А. А. МАЯКОВСКАЯ

ВЛАДИМИР МАЯКОВСКИЙНЫҢ БАЛАЧАГЫ ҺӘМ ЯШЬЛЕГЕ

Таткнигоиздат — 1955

А. А. МАЯКОВСКАЯ

ВЛАДИМИР МАЯКОВСКИЙНЫҢ БАЛАЧАГЫ ҺӘМ ЯШЬЛЕГЕ

Әнисе истәлекләре

ТАТКНИГОИЗДАТ
Яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе
Казан 1955

УРТА ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

А. А. Маяковская

ДЕТСТВО И ЮНОСТЬ
В. В. МАЯКОВСКОГО

(на татарском языке)

М. Хәмит тәрҗемәсе
Шигырьләр *Әнвәр Давыдов* тәрҗемәсендә бирелә
Редакторы *Сахаб Урайский*
Художник *Л. Зусман* рәсемнәреннән копия
Тышлык художнигы *И. Л. Язынин*

Художество редакторы *Э. Е. Дьячкова*
Техник редакторы *Г. Н. Неделько*
Корректоры *Л. Х. Шайнурова*

Наборга бирелде 3(|VI-1955 ел. Басарга кул куелды 3|IX-1955 ел. ПФ 00119. Кәгазь форматы 70×92¹|₁₆. Учет-изд. табак 3,18+рәсемнәре 0,41 таб. Басма табак 4,0+рәсемнәре 1,0 табак ,68+рәсемнәре 1,17). Табакта 68.100 хәреф. Заказ № 0264. Тираж 5.000. Бәясе 2 сум 35 тиен.

ТАССР Культура Министрлыгының Татполиграф типографиясе.
Казан, Миславский ур., йорт № 9.

Улым истәлегенә

Володя дүрт яшеннән үк китаплар ярата башлады. Ул еш кына миннән китап укуымны сорый торган иде. Әгәр мин, вакытым юклыктан, китап укый алмасам, ул борчыла башлый һәм елый торган иде. Шуннан соң мин барлык эшләремне ташлап аңа башта әкиятләр, аннары Крылов мәсәлләрен, Пушкин, Некрасов, Лермонтов һәм башка шагыйрьләрнең шигырьләрен укый торган идем. Мин аңа һәр көнне укый идем.

Әкиятләр белән ул озак мавыкмады, нинди дә булса берәр «чын нәрсә» турында укуымны сорый башлады. Володя бигрәк тә шигырьләрне ярата иде. Үзенең күңеленә ошаган шигырьләрне ул ике-өч тапкыр укыта, мин сөйләгәннәрне истә калдыра һәм яхшы, матур итеп яттан укый торган иде.

— Володя, син үзең укырга өйрәнеп җиткәч, беркемнән дә сорамассың, күпме теләсәң, шулкадәр укырсың,— ди идем мин аңа.

Володяга уеннарны апасы Оля уйлап таба торган иде. Ул энесеннән өч яшькә олырак булып, Володяга ягымлы карый, кайгыртучанлык күрсәтә иде. Володя күп яклары белән апасына охшарга тырыша торган иде; мәсәлән, әгәр Оля агач башына менсә, ул да менәргә маташа торган иде.

Без ул вакытта Грузиядә Багдади [1] авылында, Багдади урманчылыгында тора идек. Анда 1889 елның октябрендә Армениядән килгән идек. Башта без Арменияде Караклисе авылында, аннан соң элекке Эриван губернасы Никитенка авылы Александрополь урманчылыгында тордык. Минем ирем, Владимир Константинович, лесничий иде.

---

[1] Грузия ССРда, хәзер Маяковский — район үзәге.

Безнең белән бергә Дагстанлы лезгин Рәхим Оглы Имриз да килгән иде. Ул рус телен белә иде һәм урман сакчысы булып эшкә керде. Урман сакчылары урманның аерым участокларын саклыйлар иде. Багдади урманчылыгында мондый сакчылар унсигез кеше булып, Имриздан башкалары барысы да грузиннар иде.

Багдади урманчылыгы бик зур иде. Тирә-якта төрле агачлар белән капланган биек таулар. Урманда боланнар, җәйрәннәр, аюлар, кабан дуңгызлары, төлкеләр, куяннар, тиеннәр һәм төрле кошлар бик күп иде.

Урман сакчылары кайбер вакытта кечкенә җәнлекләр, кошлар алып кайталар иде. Володя җәнлекләрне бик ярата торган иде. Аның җәнлекләргә булган мәхәббәте бөтен гомере буена сакланып калды.

Ул вакытта Багдади караңгы бер авыл иде. Анда мәктәпләр дә, укытучылар да, врачлар да юк иде. Тирә-ягыбыздагы кешеләр кебек үк, без дә авырлыклар кичердек.

Балаларыбыз — Люда һәм Костя, скарлатина белән авырдылар. Доктор китерү өчен егерме җидә километр ераклыктагы Кутаис шәһәренә барырга кирәк иде.

Безнең борчылуыбызны күреп, Имриз врачны үзе алып килмәкче булды.

Ул вакытта автомобильләр юк иде. Кутаис белән Багдади арасында унике кеше сыйдыра торган дүрт ат җигелгән, дилижанс дип аталган зур экипажлар йөри иде. Дилижанс фәкать иртән генә китә торган иде. Балаларның хәлләре начарлана башлагач, Имриз Багдадидан унике километр ераклыктагы Рион станциясенә төнлә җәяү китте. Ул Кутаиска поезд белән барып җитә һәм иртән извозчик белән врачны алып килә.

Балаларның авыруы каты булды. Өч яшьлек Костя авырудан терелә алмады.

Балаларны укыту да бик авыр булды. Зур кызыбыз Люданы Тифлиска илттек. Анда безнең туганнарыбыз торалар иде. Ләкин аларда Людага торыр урын булмады. Аны ябык типтагы уку йортына урнаштырырга туры килде. Анда ул укыды да, торды да. Туган йорттан еракта, формаль тәртипләргә һәм үзенә

Володя Маяковский апасы Оля белән. 1896 ел.

бер төрле режимга буйсынып яшәүче Люда өчен дә, безнең өчен дә мондый хәл бик авыр булды. Ярый әле туганнары аның янына баргалап тордылар. Люда турында абыйсы Михаил Константинович Маяковский аеруча нык кайгыртты.

Багдадида кыш булмый торган иде. Яңгыр, юеш кар ява, көчле җил исә торган иде. Төннәр бик караңгы була иде.

Багдадида йорт тирәләре бакчалар виноград куаклары белән чолганып алынган иде. Ә ерактарак — таулар, урманнар.

Безнең йорт урман янында гына иде, ә йортларның аралары бер-берсеннән бик ерак булып, якында күршеләр юк иде.

Шакаллар посып өй янына ук килеп җитәләр. Алар төркем-төркем булып йөриләр һәм чыелдап улыйлар иде. Аларның улаулары куркыныч, ямьсез була торган иде. Мин үзем дә мондый кыргый тавыш белән өзеп-өзеп улауны бирeдә беренче тапкыр ишеттем. Балалар йоклый алмыйлар, куркалар иде, ә мин аларны:

— Курыкмагыз, безнең этләр бик яхшы, алар шакалларны якын китермәсләр,— дип юата торган идем.

Кышкы каникул вакытларында без елка бәйрәмнәре оештыра торган идек. Имриз урманнан иң матур бер зур чыршы сайлап алып кайта һәм аны бизәргә булыша торган иде. Тифлистан Люда, ә Кутаистан туганнар һәм балалары белән танышларыбыз килә торганнар иде. Балалар өчен бу көнелле бер бәйрәм була иде. Олылар белән бергәләп алар Яңа елны каршылыйлар. Балаларга бу төнне сәгать уникегә кадәр йокламаска рөхсәт ителә иде.

Балалар түземсезлек белән сәгать стрелкаларына карыйлар иде. Сәгать стрелкасы уникегә якынлашу белән, балаларга лимонад, ә олыларга вино салып, тантаналы рәвештә һәрберсен Яңа ел белән котлый идек. Яктыртылган елка бу кичне аеруча матур булып, ә тәмле пирог тагын да тәмлерәк булып тоела торган иде.

Каникуллар үтеп, уку вакыты килеп җиткәч, балалар барысы да китәләр һәм без тагын үзебез генә кала идек.

...Иртә яз. Җылы. Миләүшәләр, розалар чәчәк ата. Җимеш агачлары ак, ал чәчәкләр белән, ә гранат агачлары кызыл чә-

чәкләр белән каплана. Язгы саф һава, болытсыз зәңгәр күк йөзе, өй эче кояш нурлары белән тулган.

Балалар иртүк уяналар да:

— Әти торган, ул, тәрәзәне ачып, урман кисү өчен билет алырга килгән крестьяннар белән грузинча сөйләшеп тора. Әйдәгез, без дә торып киеник тә бакчага чыгыйк,— ди торганнар иде балалар.

Сәгать җидедә балконда иртәнге чәйне эчкәннән соң, зурлар үзләренең көндәлек хезмәтләренә тотыналар. Ә Оля белән Володя берәр төрле уен табалар яки елга буена китәләр иде. Анда Володя суга таш ыргыта һәм гадәтенчә:

— Мин сул кул белән ыргытам, ул ераграк китә...— ди торган иде.

Кечкенә вакытында Володя күбрәк сул кулы белән хәрәкәт итә иде, ә үсә төшкәч, ике кулы белән дә тигез хәрәкәт итте.

Оля белән Володя елга буеннан үзле балчык алып кайтып, аннан балконда төрле сыннар ясый торганнар иде. Балчык кипкәннән соң, сыннар таралалар иде.

Балалар кичләрен этиләре белән бергә балконда утырып җырларга ярата торганнар иде. Әтиләре аларны кочаклап ала һәм алар балалар белә торган рус көйләрен: «Румяной зарею покрылся восток», «Как ныне сбирается вещий Олег», «По синим волнам океана», «Есть на Волге утес», «Укажи мне такую обитель», «Я видел березку», украин җыры «Баламутэ выйды з хаты», грузин җыры «Сулико» һәм башка җырларны җырлый торганнар иде.

Бу әтиләре өчен ял итү була торган иде, чөнки ул иртәнге сәгать алтыдан төнге уникегә кадәр эшли торган иде.

Багдадида грузиннар гына булып, рус семьясыннан без генә идек. Безнең балалар күршедәге балалар белән уйный торганнар иде һәм грузин телен өйрәнделәр. Оля күрше кызы Наташа Шарашидзе белән дуслашты. Алар грузинча сөйләшә торганнар иде, Володя да алардан грузинча сөйләргә өйрәнде.

Балалар зурларга караганда һәрвакыт тизрәк танышалар, тизрәк дуслашалар.

Без бик гади тордык. Миңа да иртәдән кичкә кадәр эшләр-

гә туры килде. Балалар турында кайгыртырга: чисталык сакларга, балаларны укытырга, тәрбияләргә кирәк иде.

Балаларда начар характер, начар гадәтләр тумасын өчен, аларны бик җитди карарга туры килде. Мин аларны яхшы юлга салырга тырыштым. Начар йогынтылардан сакладым, аларга барын да бик түземлелек һәм тынычлык белән аңлаттым.

1898 нче елның җәйге каникуллар вакыты җитте. Люда кайтты, ул инде зур үскән. Люда яхшы рәсемнәр ясый иде, һәм ул рәсем ясарга тотынса, Оля белән Володя да аның янына килеп утыралар иде.

Люда кычкырып китаплар, шигырьләр укый, балалар белән йөрергә чыга иде.

Людадан тыш җәйгә безнең кардәшләр Киселевлар — Саша белән Леля һәм аларның абыйлары Миша килә торганнар иде.

Июльдә безнең семьяда зур бәйрәм була иде.

Володя әтисе туган көнне — 1893 нче елның 7 нче июлендә (яңа стиль белән 19 июльдә) — туды һәм шуның өчен аңа Владимир дип исем куштык. Володяның һәм әтисенең туган көнен бер көнне бәйрәм итә идек.

Безгә балалары белән кардәшләр һәм танышлар кунакка килә торганнар иде. Алар килер көнгә Имриз кошлар атып кайтырга тырыша, ә Кутаистан кунаклар килгән көнне ул бәйрәмчә киенә һәм дилижанста килгән кунакларны каршы алырга балалар белән бергә бара иде. Бу көн һәрвакыт шаушулы, күңелле һәм шатлыклы була торган иде. Безнең танышлар төрле милләт кешеләре — грузиннар, әрмәннәр, поляклар иде. Ул вакытта Польша Россия империясе составына керә иде. Варшава һәм Петроградта югары уку йортларын тәмамлаган яшьләрнең бер өлеше хезмәт итү өчен Кавказга — Тифлис, Кутаис шәһәрләренә һәм авылларга җибәреләләр иде. Грузин авылы Багдадида яшь поляк юристлары бар иде. Алар

русча яхшы сөйләшәләр иде һәм судта грузин телен русчага тәрҗемә итүчеләр булып эшлиләр иде. Алар белән безнең мөнәсәбәтебез яхшы булгач, алар еш кына бездә булалар иде. Кутаистан шулай ук безгә таныш поляклар килә торганнар иде.

Кунаклар бездә үзләрен яхшы сизәләр, иркен тоталар иде, алар рус, украин һәм грузин көйләрен җырлыйлар; поляк танецларын бииләр иде.

1898 елның 7(19) июлендә Володяга биш яшь тулды, ул күп бүләкләр алды. Бу көнгә Володя М. Ю. Лермонтовның «Бәхәс» дигән шигырен өйрәнгән иде, ул аны яхшы һәм бик ачык итеп яттан укыды, ул аның бөтенесен укый алмады, әлбәттә, ләкин биш яшьлек малай өчен ул шактый күп строфаларны укый алды:

Бөтен тирә таулар моны
Ишетеп торган,—
Казбек белән Шат тавының
Бәхәсе булган.
Чал түбәле Шат Казбекка:
— Син саклан, дигән,—
Кеше сиңа бер дә юкка
Кидерми йөгән.
Өй корыр ул итәгеңә,
Төтен җәйдерер,
Балта тавышы иңнәреңне
Яңгыратып йөрер.
Бакыр, алтын эзләп, батырыр
Тимер көрәген,
Куркынычлы эзләр ярыр,
Әрнер күкрәгең.
Томан, бөркет кенә йөргән
Кыялар аша
Караваннар үтә бүген
Сукмак, юл ясап.
Кеше хәйләкәр! Беренче юл
Кыен булса да,
Саклан! Көнчыгыш мәгърур ул,
Кеше күп анда.

Володяның укуын мактадылар.

Аның хәтере бик яхшы булып, ул бик күп шигырьләрне истә тота ала иде. Аңа А. Н. Майковның «Көтүче» дигән шигыре ошады:

Кырыс иде король Дон Педро,
Тетри иде халкы аның,
Курка иде вәзирләре,
Дон селкетсә мыекларын.

Һәм Ф. Н. Глинканың «Москва» дигән:

Гүзәл шәһәр, изге шәһәр,
Сыйдыргансың иңеңә,
Авыллар, иркен бистәләр,
Зур сарай, таш өйне дә,—

кебек шигырь юллары аеруча ошый иде.

Ул вакытта Багдадида балалар өчен бернинди культура-агарту оешмалары һәм учреждениеләре юк иде. Ул хәзер генә совет балалары өчен балалар мәйданчыклары, китапханәләр, кино, театрлар, Пионерлар сарайлары, культура-ял парклары, стадионнар бар, ә элек аларга күңел ачу урыннарын үзләренә табарга кирәк була иде.

Володя белән Оля тауларга, урманга барырга, елгада коенырга, бигрәк тә су тегермәне янында булырга яраталар иде. Анда алар крестьяннарның кукуруз тарттыруларын, тегермән суының шарлавык кебек шаулап акканын сокланып карый торганнар иде. Крестьяннар һәм аларның балалары белән танышалар һәм грузинча сөйләшәләр иде.

Урманчылыкта гадәттә эш күп була иде.

Иртән иртүк крестьяннар урман кисү өчен билет алырга киләләр. Зур ишек алды кешеләр белән тула, участоклардан урман сакчылары килә иде. Өй тирәсендә үгезләр җигелгән ике тәгәрмәчле арбалар тора торган иде.

Әтиләренә урман хуҗалыгы эше буенча күп йөрергә туры килә иде. Урманда янгыннар булгалый, агач кайрысын кимерүче кортлар килеп чыга — аларга каршы чаралар күрергә ки-

рәк була торган иде. Төрле токымдагы агач орлыклары хәзерләп, аларны Россиягә җибәрә торган идек без.

1899 нчы елда без таш йортка күчтек. Йорт торган урын «крепость» дип атала иде, ләкин иске крепостьтан йорт тирәсендәге биек балчык стеналар һәм куаклыклар үскән тирән чокырлар гына калган иде.

Владимир Константинович Маяковский. Шагыйрьнең этисе. 1893 ел.

Безнең квартира өске катта иде, ә аста — хуҗаның подвалы. Анда вино ясыйлар һәм аны шунда саклыйлар иде. Безне грузинча маджари дип атала торган виноград суы белән сыйлый торганнар иде.

Ишек алдына винолар саклый торган зур чүлмәкләрне куялар иде. Грузиядә аларны чури дип атыйлар. Алар шундый зурлар, эчләренә шул чүлмәкләрне чистартучылар, юучылар бик иркен сыялар иде.

Бу чүлмәкләрне җиргә яткырып куйган вакытларда Володя аларның эченә кереп, апасына:

— Оля, читкәрәк китеп тыңлап кара әле, минем тавыш яхшы яңгырармы икән,— ди торган иде.

Ул анда «Усал король дон Педро...» дигән шигырьне укый һәм аның тавышы калын булып, яңгырап чыга торган иде.

Бу вакытта Володяга алты яшь тулган чак.

Виноларны саклау өчен чүлмәкләрне җиргә күмеп куялар иде. Бервакытны крепостьта чүлмәкләрне күмү өчен чокыр казыганда бик иске бакыр акча таптылар. Монда элек заманда кыйммәтле нәрсәләр күмгән булганнардыр дип уйладылар.

Александра Алексеевна Маяковская.
Шагыйрьнең әнисе. 1893 ел.

Володя да, Оля да моның белән бик кызыксындылар һәм пычаклар алып шунда бик озак казынып маташтылар. Алар берничә чокыр казыдылар һәм анда бернәрсә дә юклыгына ышандылар. Шулай да алар ниндидер бер иске акча таптылар, моңа алар горурландылар һәм бик риза булдылар.

Володя үзе кечкенә булса да, зурлар арасында булырга ярата торган иде. Зурлар аның белән шөгыльләнәләр — укыйлар, сөйләшәләр, шаяралар иде. Володя зурлар уенына катнашырга ярата иде.

Шундый бер уен исемдә калган: уйнаучы шигырь укый башлый, аннан соң шигырьне укып бетермичә туктый да уйнаучыларның берәрсенә яулык ыргыта. Яулыкны алган кеше шигырьнең азагын укып бетерергә тиеш була. Володя уенга зурлар белән бертигез катнаша иде. Яки нинди дә булса бер хәрефкә күбрәк сүз табу уены башлана иде. Зурларны бу уен ялыктырса да, алар сүзләр уйлап табарга иренә башласалар да, Володя һаман сүзләр уйлап табуны дәвам итә торган иде. Бу уен аны бик мавыктыра иде.

Володя еш кына үз дигәнен булдыру өчен тырыша торган иде һәм үзенең уенны дәвам итү теләгенә зурларны буйсындыра белә иде. Мондый хәлләрдә ул уенны оештыруны үз өстенә ала һәм уйнап арыган, инде уйнарга теләмәүчеләрне дә үз ягына аудара торган иде.

Володя кызыксынучан, күңелле малай булганга, һәркем ва-

кытын аның белән уздырырга теләде. Володя бигрәк тә үзеннән тугыз яшькә зур булган туганнан туган абыйсы Миша Киселевны ярата иде. Миша Володяга зур игътибар һәм мәхәббәт белән карый иде.

Җәй көннәрендә бездә һәрвакыт укучы яшьләр күп була торган иде. Алар күңел ачу өчен урманга, тауларга чыгалар. Володя зурлардан калышмый һәм алар белән тауларга менә торган иде. Кичләрен күк йөзе ялтырап торган миллионлаган йолдызлар белән каплана иде. Оча торган йолдызларга охшаган яктырткыч коңгызлар очалар иде. Володя аларны тота да ни өчен яктыртуларын белергә тырыша иде. Ярканатлар белән маташа иде.

Эссе көннән соң салкынча кич килә, тау араларыннан саф җил исә торган иде. Беркемнең дә йоклыйсы килми. Уеннар уйлап табалар, зурлар да, балалар да, кем ничек булдыра алса шулай хор белән җырлый торганнар иде. Тирә-якта тынлык, бары тик елга чылтыравы һәм су шыпылдавы гына ишетелә.

Багдади авылыннан тиз ага торган Ханис-Цхали елгасы үтә. Анда бик тәмле форель балыгы тоталар иде һәм ул балыкны без еш кына ашый торган идек.

Гадәттә иртән иртүк өй янына урман каравылчылары киләләр иде. Володя аларга каршы йөгереп чыга да алар аны атка атландырып ишек алдына алып керәләр иде.

Имриз Володяга мондый рәхәтлекне бик еш кына эшли торган иде: ул алты яшьлек Володя атланган атны тезгененнән җитәкләп йорт тирәсендә йөртә торган иде һәм шулай итеп ул Володяны атка атланып йөрергә өйрәтте.

Безнең күршедә зур виноград бакчалары бар иде, анда виноград җыючы хатын-кызлар Володяны һәм Оляны үзләре янына чакырып алалар да: «Рус балалары, ә грузинча нинди яхшы сөйләшәләр»,— ди торганнар иде — һәм Володя белән Оляны виноград белән сыйлыйлар иде.

Виноград җыю вакыты Багдади авылында һәркайчан бәйрәм кебек була торган иде: бу урын яхшы сортлы виноград районы иде.

Һәр җәйне каникул вакытларында без бөтен семьябыз белән ерактагы урманчылыкка — Зекар минераль суларына бара торган идек. Анда таулардагы тар аралыкта гостиницаны алыштыра торган агач бараклар бар иде. Без анда ике зур бүлмә алып тордык.

Тау арасында күкерт исе килә иде. Без өскә, яшел үлән һәм чәчәкләр белән капланган яланга менә идек һәм анда саф һава сулап крокет уйный торган идек. Зур төркем укучылар белән урманда йөри идек. Йөргәннән соң шунда үлән өстенә ашъяулык җәеп бик тәмләп кичке аш ашый торган идек. Грузин сыры, йомырка, салкын сарык ите һәм кыяр бик тәмле булып тоела иде.

Тауларда кояш бату белән үк бик тиз караңгылана. Өйгә юлны факеллар белән яктыртып кайтырга туры килә иде. Володя Миша янындарак булырга тырыша иде.

Безне Имриз һәм тагы якындагы урман участогыннан килгән ике каравылчы озата торганнар иде.

Биек тауларда бик караңгы һәм куркыныч. Тирә-як тып-тын, фәкать елга шаулавы гына ишетелә. Кайчакларда юлыбызда еланнар очрый торган иде, без аларның өстенә басудан курка идек. Шушы тынлыкта һәм караңгыда без җырлаган җырлар урманда яңгырый иде.

Җәй көннәрендә саф һавада без барыбыз да яхшы тазардык, теләгән кадәр җиләк-җимеш ашадык.

1899 елның көзендә Оля Люда белән Тифлиска китте һәм апасы укый торган мәктәпкә керде. Володя апасын бик сагынды, чөнки ул Оляга нык ияләшкән иде.

Кышын буш булып, күңелсез булып кала торган иде, мондый чакларда бары тик китаплар, журналлар гына ярдәм иттеләр. Без классикларның кушымталары белән һәрвакыт «Нива» журналын яздыра идек. Бу китаплар бездә бик күп җыелды. Аннан соң «Вокруг света» һәм «Юный читатель» журналларын да ала идек. Бер елны «Родина» журналы алдык. Бу журнал Володяны бик кызыктырды, чөнки анда юмористик картиналар, карикатуралар һәм табышмаклар басыла торган иде.

Володя Маяковский Багдади авылында. 1900 ел.

Володя журналны ача да, үзе укый белмәгәч, укып бирергә Оляны чакыра торган иде. Ләкин бу журнал реакцион юнәлештә булганлыктан, без аны башка елларда яздырмадык.

Володяга җиде яшь. Ул инде яхшы укый ала һәм гимназиягә керергә хәзерләнә башлады. Ул атка атланып йөрергә өйрәнде, һәм урманчылыкларга этисе аны үзе белән алып йөри торган булды.

Мин бик борчылдым, чөнки анда юллар куркынычлы иде, урман каравылчылары: «Без аны карап йөрербез» дигәч кенә, бераз тынычлана торган идем. Урманда, урманчылыкның бер участогында, Володя беренче тапкыр электр яктысын күргән һәм бик шатланган. Анда тау арасында такта яру һәм мичкә такталары ясау заводы бар иде. Соңыннан инженер безне бу заводны карарга чакырды. Без анда көн буе тордык һәм кичен электр лампалары кабынгач кына өйгә кайтып киттек.

Володяны әлифба укырга беркем дә өйрәтмәде. Аңа алты яшь чамасы вакытта, ул көтмәгәндә генә үзеннән-үзе укырга өйрәнде. Ләкин үзенең укуы аңа бик әкрен булып тоелганлыктан, ул зурларның кычкырып укуларын сорый торган иде.

Үзенең автобиографиясендә күрсәткәнчә, Володяның шкафтан укырга алган беренче китабы «Қош караучы Агафья» дигән китап булды.

Бу балалар өчен чыгарылган рәсемле һәм зур хәрефләр белән язылган китап иде. Ул бу китапны укыды, ләкин ул аңа ошамады. Икенче укыган китабы «Дон Қихот» булды һәм ул аңа бик ошады. Бу турыда да ул үзенең автобиографиясендә яза.

Володя әле начар яза, арифметиканы да яхшы белми иде. Гимназиягә керү өчен җитди хәзерлек башларга кирәк иде.

Багдадида укытучылар юк иде, шуның өчен миңа улым белән Кутаиска күчәргә туры килде. Багдадида Владимир Константинович һәм минем анам, Володяның әбисе, калдылар.

Без якын танышыбыз Юлия Феликсовна Глушковскаяга урнаштык. Ул дәресләр бирә иде һәм Володяны да укытты.

Володя аннан бик теләп укыды. Ул балаларга белеп якын килә, Володяга да ягымлы мөнәсәбәттә булды. Володя белән

ул күп шөгыльләнде, күп укыды һәм аны дәресләр белән кызыксындыра белде.

Ләкин Кутаиста ирек һәм иркенлек булмады: ишек алды кечкенә, ул биек таш коймалар белән әйләндереп алынган, капка көндез дә бикле тора иде. Урамга чыгарга ярамый — тыела иде. Йорт хуҗасы үзенең хуҗалыгын саклап тота, чит кешеләрнең йортка кереп, анда яткан әйберләрне алып чыгып китүләреннән курка иде. Кечкенә капка да бикле була. Ул капка янына кечкенә кыңгырау куелган иде, әгәр ул шалтыраса, хуҗа үзе яки башка берәү капканы чыгып ача. Тәртип шундый иде.

Бүлмәләрдә буяулы, шомартылган идәннәргә җәелгән тар паласлар өстеннән генә йөрергә кирәк иде.

Хуҗа, карт ветеринария врачы, бәйләнчек, тупас кеше иде. Ул Володяга: «Үзең идән буйлап йөрисең, үзең җәелгән паласны да күрмисең! Син урманда түгел бит!» дип кычкырына торган иде.

Володя укый торган бүлмәнең тәрәзәсенә кенәри ябылган читлек эленгән. Володя аңа пошыну белән карый иде, чөнки ул моңа кадәр иркендә оча торган, урманда сайрый торган кошларны гына күргән иде.

Володя үзеннән сигез яшькә зур булган Юлия Феликсовнаның улы белән дуслашты. Өлкән иптәше Володяны еш кына үзе белән алып йөрде. Алар шәһәргә чыгып йөри торганнар иде.

Шимбә көннәрне урманчылыктан әтисе кайта торган иде һәм малайларның күңелен күрергә тырыша: аларны кондитер магазинында тәмле-татлы әйберләр белән сыйлый, кайвакытта циркка алып бара, извозчик белән аларны шәһәр читенә алып чыга торган иде.

Бу вакытта безнең семья өч җирдә тора иде. Барыбызга да авыр, ләкин башка юл юк — балаларны укытырга кирәк иде.

Кышкы каникуллар вакытында барыбыз да Багдадига җыела торган идек һәм анда вакытны бердәм, яхшы һәм күңелле итеп уздыра идек; язгы каникуллар да шулай уза иде.

1901 нче елның язында Люда җиде классны тәмамлады.

Аның курсны тәмамлау уңае белән без бөтен семьябыз белән Сухум шәһәренә барырга булдык. Анда Люданың дусты Туркиянең ата-аналары тора иде. Алар безне кунакка чакырганнар иде.

Без Батумга кадәр поезд белән, ә аннан соң Сухумга кадәр пароход белән бардык.

Көннәр яхшы, кояшлы иде. Кара диңгез тын һәм матур. Кояш суга төшкән кебек булып күренә иде, һәм кояш нурларының диңгездә чагылуы карап туя алмаслык матур күренеш бирә иде.

Бу сәяхәт бөтенебезне дә, бигрәк тә тәэсирләнүче, күпне белергә теләүче Володяны хозурландырды. Ул матрос костюмы кигән иде, пассажирлар белән, капитан һәм матрослар белән дәртләнеп сөйләште. Ул пароход буенча шундый тиз йөгереп йөрде, без аның артыннан күзәтеп тә өлгерә алмый идек. Аның бөтен нәрсәне күрәсе, бөтенесен карыйсы килде.

Ул вакытта Сухумда пароход пристаньга килеп туктамый иде. Безне Туркияләр семьясы каршы алды. Алар көймә белән пароход янына килеп безне алып ярга чыктылар.

Сухумда безне яхшы каршыладылар. Без бик күп йөрдек, шәһәрне карадык.

Володяны маяк бик кызыксындырды. Аңа маякның ничек төзелүен һәм ни өчен хезмәт итүен аңлаттылар: ул бик еракка яктырта һәм морякларга юл күрсәтә. Володя маяк башына менде дә Оляга:

— Кызганыч, мин үзем генә менеп түбән карамадым, син нинди кечкенә булып күренер идең икән,— диде.

Маяк Володяда шундый тәэсир калдырды ки, соңыннан, шагыйрь булгач, бу балалар өчен «Минем бу китабым диңгез һәм маяк турында» дигән китап язды. Китапның азагында ул балаларга мондый сүзләр белән мөрәҗәгать итә:

— Балалар,
сез маяк кебек булыгыз!
Кемнәр төнлә йөзә белми,
Барының да
Ут белән юлын яктыртыгыз.

Ул үзе бала вакытыннан ук үзенең эшләре белән кешеләрнең якты киләчәккә бару юлларын яктыртып яшәү турында хыялланды.

Мәктәптәге иптәшләре аның фамилиясен кыскартып «Володя Маяк» дип атауларына аның бик кәефе килә торган иде.

Сухумнан Батумга без тагын да диңгездән кайттык. Пароход бик нык чайкалды, дулкыннар пароход өстенә чәчрәде. Чайкалу балаларга зур тәэсир итмәде, аларны дулаган диңгез бик кызыксындырды. Мин бөтен юл буе каютада ятып килдем, миңа бик начар булды. Батумга авырып кайттым.

Җәйне яхшы һәм күңелле үткәргәннән соң, Люда Тифлиска — соңгы, сигезенче педагогик классны тәмамларга китте.

Мин яшь балаларым белән Кутаиска кайттым. Оляны Кутаис гимназиясенә күчерделәр, ә Володя гимназиягә хәзерләнүен дәвам итте.

Бу кышны Володяны бик яхшы яшь укытучы Нина Прокофьевна Смольнякова укытты. Аның Володя исемле тагын бер укучысы бар иде; ул укучы безгә килә иде һәм Нина Прокофьевна аларны безнең өйдә икесен бергә укытты. Безнең Володя зур сәләтлелек күрсәтеп һәм күпне белергә тырышып, бик әйбәт укыды.

Декабрь азагында Володя дифтерит белән авырды. Аңа прививка ясадылар һәм авырудан саклану өчен Оляга да укол ясадылар. Аларны мин тәрбияләдем.

Володя бераз сәламәтләнә башлагач, аның кровате янына елка куйдык. Ләкин бу аны юатмады, аның тизрәк торасы килде.

Бәйрәм каникулына Тифлистан Люда кайтты, ә Багдадидан әтиебез килде. Шулай да күңелле булмады: Володя өчен борчылдык.

1902 нче елның маенда Володя гимназиягә керү өчен имтихан бирде.

Мин аңа күк сукнодан озын чалбар, ак матрос күлмәге тектем, аның җиңенә күк төстәге якорь тегеп куйдым һәм тасма-

сына «Матрос» дип язылган бескозырка сатып алдым. Володяга бу костюм бик ошады.

Хәзерлек классына ул имтиханны отличнога бирде, ләкин имтихан алучы священникның «око» нәрсә ул дип соравына Володя дөрес аңлатма бирмәгән. Ул чиркәү-славян телендә күзнең «око» дип аталуын белмәгән, «өч кадак» дип җавап биргән. «Ока»— грузинча авырлык үлчәве — өч кадак дигән сүз.

Имтиханның ахыргы көнендә Володяның температурасы күтәрелде, ул корсак тифе белән авырды. Мин аның белән Кутаиста калдым, ә Люда белән Оля Багдадига, әтиләре янына киттеләр.

Володя бик каты авырды һәм без бик борчылдык. Аны Анна Константиновна апа тәрбияләде. Ул хәрби госпитальдә сестра булып эшли иде. Володя аны бик яратты, Анюта апа дип йөртте.

Володя янына доктор атнага ике мәртәбә килде һәм аңа ярдәм итү өчен бөтен чараларны күрде. Ул: «Әгәр ярдәм кирәк булса, миңа хәтта төнлә дә килегез»,— диде.

Володяга тавык ите белән пешкән аш кына бирә идек, ә уңайлана төшеп, ашыйсы килә башлагач:

— Мин тавык ите телим! Докторны чакырырга барыгыз,— дип сорый иде.

Төнге сәгать уникe иде, шулай да Володя:

— Доктор бит үзе төнлә булса да килергә ышандырды,— дип докторга баруны ныклап таләп итте.

Володяның ятып торасы килмәде. Ул бик хәрәкәтчән һәм түземсез иде. Һәрвакыт үзенә китап укуны сорады.

Ахырда Володяның сәламәтлеге яхшыра башлады. Врач килде һәм Багдадига барырга рөхсәт бирде.

— Ләкин сакланырга, кайнамаган су эчмәскә!— диде.

Бу сүзләрне Володя бервакытта да исеннән чыгармады.

Кутаиста водопровод юк иде, шәһәрдә яшәүче халык Рион елгасы суын ачуташ белән зарарсызландырып эчәләр иде. Кутаиста без һәрвакыт кайнаган су эчтек; ә Володя өйдән читтә берәр җирдә кайнамаган су эчкән булса кирәк.

Җәй буе Багдадида торып Володя яхшы тазарды.

Көзен барлык семьябыз белән, этиләреннән башка, Кутаиска күчеп килдек. Үзебез белән минем әнине — авыру карчык Евдокия Никаноровнаны да—алып бардык. Сигезенче классны бетереп Люда да безнең яныбызга кайтты.

Володя гимназия формасы киде һәм 1 нче сентябрьдә элек этисе һәм агасы укыган гимназиягә укырга китте. Оля икенче класска күчте. Уку елының икенче яртысында Люда мәктәпкә укытучы булып керергә теләде һәм этисе аны шушы эшкә урнаштырды.

Безнең дус семьябызда бары тик этиебез генә юк иде. Аның бер үзенә генә урманчылыкта торырга туры килде. Ул балаларны бик сагынды һәм аның Кутаиска килүе чын бәйрәм булды. Туганнар һәм танышлар да киләләр иде. Этиләре Кутаиска килгән вакытта балаларның өйдә булуларын яратты. Ул балаларның кәефләрен табарга тырышты, зур яшьтәге балалар белән театрларга һәм кичәләргә йөрде.

Володя белән Оля яхшы укыдылар, алар бишле билгеләре генә алалар иде.

Гимназиягә аларны Угрюм исемле кечкенә эт озата бара иде. Ул юлны бик яхшы белгәнгә, балаларны озатканнан соң, һәрвакыт өйгә кайта иде. Ләкин бервакыт ул берничә көн югалып торды. Володя да, Оля да бик нык борчылдылар, аны бөтен җирдән эзләделәр һәм эт кайткач бик шатландылар.

Без барыбыз да терлекләрне бик ярата идек.

Люда Тифлистан кайткач, өйдә күңелле булып китте. Аның янына урта уку йортларын тәмамлаучы яшьләр, студентлар киләләр. Алар укыйлар, бәхәсләшәләр, бииләр, күңел ачалар иде. Оля белән Володя янына да укучылар килә иде.

Без госпитальдән һәм Куринский полкы казармаларыннан ерак түгел Читава йортында тордык. Танышлардан рояль сатып алдык һәм Оля музыкага өйрәнде. Аңа укытучы килә иде.

1903 нче, Яңа елны Кутаиста каршыладык. Бик күп яшьләр һәм туганнар җыелды. Елка ясадык. Музыка уйный белүче танышлар рояльдә уйнадылар, бөтенесе дә биеделәр, төрле уеннар уйнадылар.

Без шат күңелле яшьләргә куаныч белән карап тордык һәм аларга күңел ачу кичәсе оештыруыбыз өчен бик канәгать булдык.

Бәйрәм бик тиз үтте.

Эш көннәрендә бөтенесе дә үз эшләре белән шөгыльләнделәр, бик күп китап укыдылар. Без Горький, Чехов, Короленко һәм башка язучыларның яңа әсәрләрен ала идек. Яңа китаплар бөтенесен дә кызыктыра иде. Журналлар, газеталар укый идек. Әдәбият һәм политик вакыйгалар турында сөйләшә идек, фикер алыша һәм бәхәсләшә идек.

Ул елның язында йөрәк авыруыннан Володяның әбисе — Евдокия Никаноровна Павленко үлде.

Җәй үткәрергә без барыбыз да Багдадига кайттык, анда иркен һәм рәхәт иде.

Ул җәйне Володя бигрәк тә күп укыды һәм астрономия белән мавыкты — «Вокруг света» журналына кушымта итеп йолдызлы күкнең картасы бирелгән иде. Кичләрен Володя чалкан ятып, якты һәм эре йолдызлар белән куе итеп бизәлгән күкне күзәтергә ярата торган иде.

Соңыннан үзенең бер шигырендә ул болай дип язды:

Әгәр мин
шагыйрь булмасам,
булыр идем
мин
йолдыз санаучы.

Без һәрвакыттагы кебек урманчылыкның ерак урыннарында булдык. Зекар минераль суларына бардык, ял иттек.

Яңа уку елы башлануга Кутаиска кайтырга кирәк иде.

Квартираны Гегутский урамы, 35 нче номерлы Чейшвили йортыннан алдык. Хәзер ул Цулукидзе урамы дип атала. Бу урамда элек иптәш Сталин белән бергә революцион эш алып баручы, революционер, большевик Александр Цулукидзе торды.

Чейшвили йортында дүрт бүлмә бар иде. Коридорның уң ягындагы зур бүлмә күчереп йөртелә торган ширма белән бү-

ленгән иде. Ширма артында Володяның кровате һәм тәрәзә янында өстәле торды. Аерым бүлмә кебек булды. Укыйсы килгәндә яки йокларга ятканда Володя ширманы кучерә торган иде.

Володя үз әйберләрен җыйнак тотты, аларны теләсә кая ташламады. Китаплары өелгән көйгә өстәлдә һәм тәрәзә төбендә тора иде. Ул рәсемнәр ясады, агачтан кисеп әйберләр эшләде, китаплар төпләде һәм соңыннан барысын да җыештырып куя торган булды. Володя тәртип булуны яратты һәм әйберләрен җыештырып кую турында аның исенә төшерү бер дә кирәк түгел иде. Идәндә кәгазь кисәкләре, пычкы чүпләре, шакмаклар калганда, ул аларны һәрвакыт үзе себереп куйды, аның артыннан миңа бервакытта да җыештырырга туры килми иде.

Аның бу гадәте бөтен гомере буена сакланып калды. Ул олы кеше булгач та, үзенең шигырьләрен уку һәм докладлар ясау өчен Москвадан Советлар Союзының төрле шәһәрләренә йөрергә киткәндә бүлмәсен үзе һәрвакыт тәртипкә салып китә торган иде.

Володяның әтисе урманчылыктан безнең янга килгәч:

— Володя нәрсә белән шөгыльләнә, нәрсә эшли?— дип сорый торган иде.

Володя аңа үзе төпләгән китапларны, агачтан кисеп ясаган әйберләрен, рәсемнәрен күрсәтә торган иде. Ул кирәкмәгән әйберләрдән нинди дә булса файдалы әйбер ясарга ярата торган иде.

Володя югары классларда укучы һәм яшь ягыннан да үзеннән зуррак булган күрше грузиннар белән танышты. Барыннан да ешрак безгә Коля Андриадзе, Ефрем Закарая һәм Кихо Мурусидзелар керә торганнар иде. Оля да алар белән дуслашты.

Ул елны Люда шәһәр мәктәбендә укытты: кичләрен, атнага өч мәртәбә, художник Краснухага рәсем ясау дәресләренә йөрде. Ул Строгановск художество-промышленность училищесына укырга керергә хәзерләнә иде.

Люда Володяның рәсемнәрен художникка күрсәтте. Аңа рәсемнәр ошаганнар һәм ул Володяны түләүсез укытырга

булды. Володя апасы белән укырга йөрде һәм тырышып өйрәнде.

Бездә укучы яшьләр җыелган вакытта һәм биюләр башлангач, Володяны да биергә чакыра торганнар иде, ул биергә теләми, күрше йортка иптәшләре янына китә һәм анда городки уйныйлар, һәм бу уенны ул бик ярата иде.

Укыган китаплары буенча Володя үзе уйлап чыгарган башка уеннарны да уйный торганнар иде.

Күп еллардан соң бу турыда ул «Мексика» дигән шигырендә искә төшерә:

Исеңдәме,
        Кутаиста
    Артыннан клумбаның
агулы
        уктан

аттык
        без
            кораблена Колумбаның?

Багдадига киткәнче яз һәм җәй көннәрендә Володяның яратып йөргән урыны Рион елгасы буе булды. Ул анда су коенды, иптәшләре белән уйнады. Бервакыт ул суга бата башлаган, су коенучы солдатлар гына аны коткарганнар.

Володя үзенең җитлеккән булуы һәм белеме белән бөтен кешене шаккатыра иде. Инде шушы елларда ук ул һәр кешегә үзенең аерым мөнәсәбәтен белдерә иде. Селезневлар семьясына барырга кушсаң, ул бик риза була иде. Юрист Николай Платонович Селезнев университет бетергәннән соң үзенең эшләгән һәм торган урыннары — Петербург һәм Себер турында кызыклы итеп сөйли иде. Володяга ул иркәләп, игътибар белән, зур кызыксыну белән карый, аны үзенең дусты итеп эндәшә иде; Володя белән шашка уйный, аны шахмат уйнарга өйрәтә иде.

Володяны танышларыбыз семьяларындагы яшьтәшләре янына алып барырга чакырсам, ул:

— Мин аларда нәрсә эшләрмен? Аларда күңелсез,— дип каршы килә иде.

Китап укуны яратучылар безгә җыелуны дәвам итәләр иде: Кутаис урманчылыгы ярдәмчесе Суворов хатын-кызлар өчен булган югары курсларны тәмамлаган хатыны белән килә иде. Алар Петербургтан бик күп китап алып килгәннәр иде. Без бергәләп Кутаиска китаплар, журналлар яздырып ала идек, укый һәм укылганны тикшерә торган идек. Володя һәрвакытта да тыңлап утырырга ярата иде, кайвакытларда сораулар бирә һәм тикшерүдә катнаша иде.

Ольга Владимировна,
шагыйрьнең апасы. 1902 ел.

Иптәшләренә карата булган мөнәсәбәттә дә аның характеры ачык күренде. Ул грузин малайлары белән дуслашты. Уйнаганнан соң өйгә йөгереп кереп ул миннән: иптәшләрне чәй эчәргә һәм кичке ашка чакырырга мөмкинме?— дип сорый торган иде. Володя пончик ашарга ярата иде. Мәктәптә иртәнге аш өчен аңа акча биргәндә, ул иптәшләрен дә сыйлар өчен акчаны күбрәк сорый иде.

Балалар Месхишвили труппасы уйнаган театрга йөрергә яраттылар. Кутаиска Петербургтан, Москвадан, Тифлистан ул заманның атаклы артистлары еш кына киләләр иде.

Вакыт тиз үтә иде... 1904 елның Яңа ел бәйрәмен без Кутаиста каршыладык. Яңа елны каршылау өчен безне клубларга чакырдылар. Бу клублар хәрбиләр өчен иде. Бу көнне

без балаларның үзләрен генә калдырып китәргә теләмәдек, аларның иптәшләрен үзебезгә чакырдык, елка оештырдык һәм бу кичне без балалар, дуслар, туганнар белән өйдә үткәрдек.

Бу ел авыр булды.

1904 елның январенда рус-япон сугышы башланды. Барлык кешеләрнең дә кәефе борчулы булды. Госпитальдә эшләүче Анюта апа да безгә килде. Ул яраланучылар турында, мобилизация турында күп сөйләде.

Володя Селезнев янына баргач аның белән сугыш турында сөйләшә, стенада эленеп торган карта буенча карап рус эскадрасының алга бару юлын күзәтә иде.

Җәй үткәрү өчен без тагы урманчылыкка киттек һәм Багдади янындагы Нергиети авылында тордык.

Володя бик кызыксыну белән даими рәвештә газета-журналлар укыды. Аларны без үзебез яздырып ала идек. Бу вакытта аңа унбер яшь иде. Заводтагы таныш инженер да үзенең бик күп газета һәм журналларын бер көнгә безгә калдырып китә иде.

Багдадига почтаны дилижанс белән көндезге унике сәгатькә китерәләр иде. Нергиети Багдадига дүрт километр. Володя почта алу өчен көн саен Багдадига барып йөрде. Ул юл буена газета укып кайта торган иде. Шосседа иркенләп йөрергә була, анда көчкә-көчкә генә өстерәлеп арба килә, сирәк-сирәк атка атланган кешеләр үтеп киткәли иде.

Володя алып кайткан газета һәм журналларны өйдә кычкырып укый идек. Ул да тыңлый иде.

Володяның ничек кенә булса да күбрәк укыйсы килә иде. Ул журналлар, китаплар алып, этләрен чакырып, кесәсенә җимешләр тутырып, ә этләре өчен икмәк алып бакчага чыгып китә һәм агач төбенә барып ята иде. Вега һәм Бостон исемле этләр дә аның янына ук чирәмгә ятып аны «каравыллыйлар» иде. Ул анда вакытын тыныч уздыра, күп укый һәм аңа беркем дә комачауламый иде.

1904 елның августында Люда Москвага укырга китәргә җыенды. Аны этисе озатты. Әтисенең үзенең Москваны күрәсе килде һәм Люданың зур шәһәрдә ничек итеп урнашуы белән дә

Володя Маяковский, Кутаис гимназиясенең
2 нче класс укучысы. 1903—1904 ел.

танышасы килде. Люда анда Тифлиста үзе белән бергә укыган дусты Т. А. Плотникова семьясының квартирасына туктаган.

Люда Строгановск художество-промышленность училищесына керү өчен конкурслы сынауны үткән.

Без әтиләренең Москвадан кайтуын түземсезлек белән көттек. Ул безгә Москва турында, юл турында бик күп кызык нәрсәләр сөйләде.

Володя әтисенең сөйләвен зур кызыксыну белән тыңлады һәм Москва турында кабат-кабат сорашты. Аны бөтен нәрсә кызыксындырды. Шуннан соң Москва аны һәрвакыт үзенә тартты.

Володя икенче класска, ә Оля дүртенче класска күчте. Люда киткәннән соң алар үзләрен зурлардай хис итә башладылар. Апалары белән хат язышып тордылар, күп укыдылар, җәмәгать тормышы белән, хәзерге һәм үткән тормыш белән кызыксына башладылар. Мин Володяга безнең борынгы буыннар турында сөйли идем.

Бабай Константин Константинович Маяковский Ахалциха шәһәрендә шәһәр идарәсендә эшләгән. Ул рус милләтеннән булган, аның борынгы буыннары Запорожье Сече дип аталган урындагы казаклардан чыкканнар.

Володяның бабасы Алексей Иванович Павленко — минем әтием — украинлы, элекке Харьков губернасыннан. Аның туганнары бары тик украин телендә генә сөйләшә иделәр. Бабай Кубаньда, 155 нче Кубань пехота полкында хезмәт иткән, аннан соң Армениягә күчерелгән. 1877—1878 елгы рус-төрек сугышы вакытында ул капитан дәрәҗәсендә булган хәлдә Эрзерум шәһәрендә тиф авыруыннан үлгән.

Әби Ефросинья Осиповна Маяковская — кыз вакытындагы фамилиясе Данилевская — язучы Г. П. Данилевскийның туганнан туган сеңелесе — Феодосия шәһәрендә туган. Әбисе Евдокия Никаноровна Павленко, кыз вакытындагы фамилиясе Афанасьева — минем әнием яшь вакытында Кубаньда, Герновское дигән авылда яшәгән, аннан соң ире белән Армениягә,

Джалал-Оглы дигән урынга күчеп килгән, чөнки Кубань полкы анда күчерелгән булган.

Володя минем сөйләгәннәрне дикъкать белән тыңлап утыра иде. Ул әбисе Евдокия Никаноровнаны гына белә иде. Башкалар турында ул:

— Мин аларны бервакытта да күрмәдем һәм белмим,— ди торган иде.

Һәм соңыннан бу сүзләрне бервакытта да исенә төшермәде. Ләкин аңа унбер яшь вакытта безнең семьяның үткән заманы турында минем сөйләгән барлык сүзләремне ул онытмаган һәм соңыннан, күп еллар үткәннән соң, «Безнең яшьләргә» дигән шигырендә болай дип язды:

Мин —
бер бабам ягыннан казак,
икенчесеннән — сечевик,
ә тумышым белән
грузин.

1905 елның 9 январенда беренче рус революциясе башланды. Кутаиста да, бөтен илдәге кебек үк, эшчеләр, солдатлар һәм укучылар арасында чуалыш башланды.

Володя үзенең гимназиядәге иптәшләре белән грузин телендә «Варшавянка», «Кыю атлыйк, иптәшләр!» дигән һәм башка революцион җырларны өйрәнде.

Революцион яшьләр һәм солдатлар, шаулап торган Рион елгасы буенда 1905 елның язында сходкага җыелалар иде. Анда кайнар речьләр сөйләнә иде. Бу сходкаларда Володя була торган иде.

1905 елның июнь башында Люда Москвадан каникулга кайтты һәм без җәйне үткәрү өчен бөтенебез бергә Багдадига киттек.

Люда легаль һәм легаль булмаган политик китаплар алып кайтты һәм аларны Володяга бирде, чөнки ул аны бик үскән һәм политик мәсьәләләр белән кызыксынучан дип тапты. Володяга ул вакытта унике яшь иде.

Люда Володяга укырга ул вакытта тыелган ике шигырь

Шагыйрьнең апасы Людмила Владимировна Маяковская. 1905 ел.

бирде. Ул шигырьләрнең берсе революцион восстаниене бастырырга җибәрелгән солдатларны патша хөкүмәтен тыңламаска чакырган түбәндәге шигырь иде:

Тукта син, иптәш! Уйлап кара син,
Мылтыгыңны ыргыт бер якка,
Ишет эшче туганың авазын,
Халык тавышын ал син колакка.
Мылтыгыңны кемгә дип кордың?
Нинди дошманга дип атасың?
Туганыңны хиссез үтердең
Һәм кыйныйсың анның баласын.
Ә авылда синең үтерәләр

Маяковскийлар семьясы. Басканнардан: шагыйрьнең әтисе Владимир Константинович Маяковский һәм шагыйрьнең зур апасы Людмила Владимировна. Утырганнардан: шагыйрьнең әнисе Александра Алексеевна һәм кече апасы Ольга Владимировна. Уртада — В. Маяковский, Кутаис гимназиясенең 3 класс укучысы. 1905 ел.

Үз якыннарыңның барысын...
Ишетәсеңме, җилләр китерәләр
Сиңа, солдат, алар каргышын...
Рус илендә канга буялган
Таш урамнар бүген азмы соң?..
Анда үксеп елый балалар...
Меңнәрчә тол каргый язмышын...
Яшь баласы мәете өстендә
Ана елый чәчен өзгәләп,
Ачы нәләт аның телендә,
Бел син, солдат, сиңа ул нәләт!
Балаларның ата-анасын
Тартып алдың, атып үтердең,
Бел син, солдат, дөрләп янасың
Каргышында миллион үксезнең.
Тукта син, иптәш, син уйлап кара,
Мылтыгыңны ыргыт җиргә син.
Бас син тизрәк безнең сафларга,
Азатлыкны яула бергә син.
Ташла мылтыгыңны, дөньяга кычкыр:
Үтерүче түгел мин, халык малае.
Бирәм мин сезгә, бирәм ачкычны
Ачарга канечкеч патша сараен.
Уянды пехота, матрос кузгалды,
Уянды казакларның көче бары.
Безнең күңелләрнең ирекккә сусавы
Җимерер патшаның ялчыларын.
Тукта син, иптәш! Уйлап кара син,
Мылтыгыңны ыргыт бер якка,
Ишет эшче туганың авазын,
Халык тавышын ал син колакка.
Чит җирдә сугышып, коллыкны яклап
Үлгәнче бер тамчы су сорап,
Халкыңа мәңгелек бәхетне яулап
Урамда үлүең яхшырак!

Икенче бер шигырьдә патша Николай II мыскыл итәлә иде:

Безнең шәһәр Невада,
Ника дигән берәү анда
тора.
Ул акылын югалтып,
Аягын тыпырдатып
акыра.

Кычкыра ул: «Валлаһи,
Эшләтегез әллә ни,
Бирмим ирек!
Бар да булыр искечә,
Мин патшамы, сезнеңчә,
Юкмы,— диеп.
Хаким булырмын туйганчы,
Бар ирекне куганчы
Җирдән.
Барысын себерермен, ләкин,
Конституция сезгә мин
Бирмәм.
Миңа әнием әйткән
Үрнәкне гел этидән
Табарга.
Кем тәхетемә кул сузган,
Барысын бастырырмын кызган
Табага.
Әйтсәләр дә күбесе
Минем башым, янәсе,
Күчән дип,
Бик күп кеше оят дими,
Минем сыбызгыга бии,
Көчәнеп.
Земецларга эләгер,
Кара, нәрсә теләгәннәр!
Уңмаслар!
Парламент кирәк икән.
Борыныгыз җитәр микән?
Булмас ла!
Ә минем борыныма сез
Чиертергә булдырмассыз
Кайчан да,
Мин әйтсәм: Әй, җитәр, сез
Китегез!— дип, китәрсез
Кая да.
— Әй син, патша Николай,
Әйт әле син, ник алай
Өрәсең?
Син тыңласаң киңәшне,
Зыян булыр диепме
беләсең?
Земецларны ишет син,

Алар безнең җир кешесе,
Яшиң безнең җирдә.
Юкса башка булыр юлың:
Немецка [1] хатының, улың,
Анаң белән бергә!

Бу легаль булмаган шигырьләр Володяга зур тәэсир иттеләр. Володя үзенең автобиографиясендә бу шигырьләрне исенә төшереп болай дип язды: «Бу революция иде. Бу шигъри революция иде. Башымда шигырь һәм революция ничектер берләшәләр иде.

Август аенда Люда яңадан Москвага китте. Ул китәр алдыннан без бөтен семьябыз белән рәсемгә төштек.

Уку йортларында укулар начар бара иде. Без Людадан дулкынландыра торган һәм кызыклы хатлар ала идек. Үз чиратыбызда без дә аңа үзебездәге вакыйгалар турында хәбәр итә идек. Оля белән Володя апаларына бөтен нәрсә турында язып торды. 1905 ел азагында язылган бу хатлар сакланганнар. Аларның берсендә Володя болай дип яза:

«Кадерле Люда!

Сиңа озак язмаганым өчен зинһар гафу ит. Исәнлегең ничек? Сездә дәресләр буламы? Бездә биш көнлек забастовка булды, ә аннан соң дүрт көн гимназия ябык торды, чөнки без чиркәүдә «Марсельеза» җырладык. 15 ндә Кутаиста тәртипсезлекләр булуы көтелә, чөнки новобранецларны җыячаклар.

11 ндә биредә поварларның забастовкалары булды. Газеталарда язылуынча, сездә дә зур тәртипсезлекләр күренә...

Сине бик нык үбәм. *Энең Володя*».

Икенче хатында апасына Володя түбәндәгеләрне хәбәр итте:

«Кадерле Люда!

Без синең хатыңны 1 ндә алдык һәм шунда ук бөтенебез бергәләп җавап язарга утырдык. Хәзергә Кутаиста куркынычлы бернәрсә дә булмады, шулай да гимназия һәм реальное

[1] Николай II нең хатыны немец милләтеннән булуга төртеп әйтә.

баш күтәрделәр, әйе, баш күтәрүнең кирәге бар иде. Гимназиягә пушкалар төзәделәр, ә реальноеда тагын да яхшырак эшләделәр. Әгәр бер тавыш чыкса, бөтенесен җимереп бетерәчәкбез дип, анда пушкаларны ишек алдына куйдылар. Тифлис шәһәрендә казаклар яңа «искиткеч» җиңүгә ирешкәннәр. Анда Николай патша рәсемен күтәреп тантаналы йөргәннәр һәм бу процессия вакытында гимназистларга бүрекләрен салырга кушканнар. Гимназистлар тыңламагач, казаклар аларга пуля белән җавап биргәннәр. Бу кыйнаш ике көн дәвам иткән. Патшаның башыбозыкларын беренче тапкыр Гуриядә җиңделәр, анда бу этләрнең ике йөзләбе үтерелде. Кутаис та кораллана, урамнарда һаман «Марсельеза» тавышлары яңгырый. Үтерелгән Трубецкий[1] һәм Тифлис эшчеләренә оештырылган панихида вакытында биредә дә «Сез урынсыз корбан булдыгыз» дигән җырны җырладылар.

Миңа да яз. Сине бик нык үбәм. *Энең Володя».*

1905 елда Кутаис һәм гимназия тормышындагы вакыйгалар шулай ук Кутаис хатын-кызлар гимназиясенең 5 классында укучы Оля хатларында да чагылдырыла иде. Ул Москвага апасына болай дип язды:

«...Бүген синең ачык хатыңны алдым. Володя 3 нче класска күчте, ул сиңа билгеледер инде.

Бездә, Кутаиста полицейскийларны һәм шпионнарны эт урынына үтерәләр. Өченчекөн ике полицейскийны һәм бер приставны яраладылар. Аларның берсе үлде, ә икесе тере әле...

Безгә өстәлгән ун сумны киметү турында бүген бездә сходка булды[2]. Мин, әлбәттә, беренче булып таләп куярга риза булдым. Мин бүген иртәдән бирле Каргановлар[3] белән өйләргә кереп, сходкага чакырып йөрдем. Мин бүген сходкага барам дип әнигә әйттем һәм әни рөхсәт итте, анысы әйбәт.

...Бүген дәрес алдыннан гимназистлар гыйбадәт кылырга

---

[1] Москвада черносотенцлар тарафыннан үтерелгән Москва университеты ректоры.

[2] Революциягә кадәр урта мәктәптә уку түләүле иде. Бу очракта укучылар уку өчен түләүне арттыруга каршы протест белдерәләр.

[3] Карганов күренекле революционер иде. 1919 елда ул, 26 Баку комиссарларының берсе буларак, англо-француз интервентлары тарафыннан явызларча атып үтерелә. О. В. Маяковская Карганов сеңелесенең дусты була.


Дорогая Люда!
Прости пожалуйста что я такъ долго не писалъ. Какъ твое здоровье? Есть ли у васъ занятия? У насъ была три дневная забастовка, а послѣ была гимназия закрыта четыре дня такъ какъ мы пѣли въ церкви марсельезу. Въ Кутаисѣ 15го ожидаются безпорядки потому что будетъ наборъ новобранцев. 11го здѣсь была забастовка поваровъ. По газетамъ видно что и у васъ большия безпорядки. Кострова и директоръ уходятъ. Кострова послѣ 20го хотѣла ѣхать въ Москву но сама Бабелыгъ чѣмъ то вродѣ жида. Прости пожалуйста за ошибки (если есть) Пиши.

Цѣлую тебя крѣпко
твой братъ

Володя

В. Маяковскийның апасы Л. Маяковскаяга Кутаистан Москвага язган хаты. 1905 ел.

тиешләр иде, ә алар Тифлиста үтерелүчеләргә панихида үткәрүне мәҗбүр иттеләр».

«...Монда реалистлар һәм гимназистлар хәрби положение бетерелгәнче баш күтәрәләр. Беләсеңме, полиция шулкадәр ерткычланды.

Реаль училищеның иске бинасына «кирәк булса-нитсә» дип пушкалар куелган. Реалистларга теләсәләр дә, теләмәсәләр дә баш күтәрергә туры килә, әйе, минемчә дә, ата-аналарның берсенең дә үз балаларын укырга җибәрәселәре килмәс. Бездә бер атна буе забастовка булды, ә кичә укулар башланды, һәр класстан биш-алты укучы укырга килә.

...Речьләр сөйләнеп беткәннән соң, без урам буйлап «Марсельеза» җырлап бардык, ләкин полиция комачауламады. Бездә хәзер хулиганнар урам буйлап Николай патша рәсемен күтәреп йөрергә җыеналар. Ул вакытта, әлбәттә, монда да Тифлистагы кебек вакыйга булачак».

Бүтән хатларында Оля болай дип хәбәр итте:

«... Без бүген Трубецкийга, шулай ук Тифлиста үтерелүчеләргә панихида үткәрүне таләп иттек.

Ирләр гимназиясендә дә панихида үткәрүне таләп иттеләр, шуннан соң чиркәүдә үк алар «Сез урынсыз корбан булдыгыз» дигән җырны җырладылар. Хәзер ирләр гимназиясе ябылды».

«...Володя бүген беренче тапкыр гимназиягә китте, гимназистлар беренче көнне үк киңәшмә уздыру өчен үзләренә зал бирүне таләп иттеләр. Алар начар укытучыларны, шулай ук директорны да бугай, эштән алуны таләп иттеләр, әгәр бу таләпләре үтәлмәсә, баш күтәрәчәкләр».

Унике яшьлек Володя аеруча активлык белән үзе кичергән вакыйгаларга бөтенләй бирелде. Ул бу көннәрдә шатланып һәм горурланып йөрде. Еш кына: «Яхшы!» дип куя иде. Революцион вакыйгалар белән ул гаять кызыксына иде, шуңа күрә дә шәһәрдә булган бөтен хәлләрне белеп торды.

Володя үзеннән зур иптәшләре — революционерлар белән дуслашты. Ул алардан Тифлиста, Бакуда, Кутаиста, Чиатурада иптәш Сталинның революцион эш алып баруын ишетте. Ул вакытта бу турыда яшерен генә сөйләшергә туры килә иде,

әлбәттә. Кутаиска килгән вакытта иптәш Сталин А. Цулукидзеларда була торган иде, Цулукидзе да бездән якын гына, Гегутский урамында тора иде. Анда социал-демократлар комитеты урнашкан иде. Володя урманчылык буенча йөрү өчен этисенә бирелгән казна мылтыкларын комитетка илтеп бирде.

Володя Москвада черносотенцлар тарафыннан үтерелгән большевик Н. Э. Бауманны күмү уңае белән Кутаиста 1905 елның октябренда оештырылган политик протест демонстрациясендә катнашты.

Володя 1905 елда укыган кайбер китаплар һәм брошюралар бездә сакланып калганнар. Ул үзе укыган политик эчтәлекле китапларын һәм брошюраларын берничә җыентык итеп туплап зур тырышлык белән төпләп куйды.

Шундый бер җыентыкка биш брошюра тупланган.

Җыентык Ф. Энгельсның «Франциядә һәм Германиядә крестьян мәсьәләсе» дигән брошюрасы белән башланып китә. Башка бер кечкенә җыентыкка ике брошюра урнаштырылган, шуларның берсе В. Либкнехтның «Маркс турында истәлекләр» дигән брошюрасы.

Укучы яшьләрнең революцион көрәшендә катнашкан Оля да революцион әдәбият укый иде. Ул вакытта Москвага апасына язган хатларның берсендә ул үзе укыган китапларның исемнәрен әйтеп яза:

«...Мин хәзер бик кызыклы китаплар укыйм. Мин үземә китаплар сатып алдым: «Хатын-кызларның хәзерге һәм киләчәктәге хәлләре», «Бетсен социал-демократлар», «Япониядә социализм», «Работникларның программалары турында», «Нәрсә ул эш көне», «Германия эшчеләр партиясендә марксизм идеяләре», «Буржуазия, пролетариат һәм коммунизм», «Акыл ияләре арасында». Мондый китапларны Володя да үзенә 10 данә сатып алды».

Бу әдәбиятны, ул үзенең автобиографиясендә язганча, башын да күтәрми укый торган иде. Бу китаплардан укыганнарын ничек кабул итүе турында ул болай дип язды: «Фактларны чишүдә, дөньяны системага салуда социалистларның сәләтлелеге мине бөтен гомерем буена таңга калдырды».

Безнең белән аралашучы кешеләрнең күбесе безгә, сез Володяга бу яшендә үк артык ирек һәм бәйсезлек бирәсез, дип әйтә торганнар иде. Аның ул чор сорауларына һәм таләпләренә җайлашып үсүен күреп, мин аңа теләктәшлек иттем һәм аның омтылышын дәртләндердем.

Люда Москвадагы вакыйгалар турында: Бауманны күмү, Преснядагы сугышлар турында барысын да бик ачык итеп безгә язып торды... Володя белән Оля аңа Кутаистагы демонстрацияләр, митинглар, забастовкалар турында яздылар. Бөтен җирдә уку тукталды, һәм без февраль азагында Люданың өйгә кайтуын көттек.

1906 елның 19 февралендә безнең семьяга авыр кайгы килде. Каны агуланудан котелмәгәндә әтиебез үлде.

Кутаис урманчылыгына билгеләнгәнлектән, ул Багдади урманчылыгы эшләрен башка кешегә тапшырырга җыена иде. Барыбыз да бергә торырбыз дип без бик сөенгән идек. Ләкин бу уйларыбыз тормышка ашмады. Владимир Константинович кәгазьләр теккәндә, бармагына энә чәнчелгән һәм аның бармагы шешеп китте. Ул аңа игътибар итмичә урманчылыкка китте, анда аңа тагы да начаррак була башлаган. Ул начар хәлдә кайтты. Операция ясарга инде соң иде. Берничек тә ярдәм итеп булмады... Без яраткан, безнең өчен кайгыртучанлык күрсәткән, балаларның әтиләрен — иремне югалттык.

Владимир Константинович Багдади урманчылыгында унҗиде ел эшләде. Анда торучы грузиннар белән ул бик яхшы мөнәсәбәттә булды. Ул грузинча бик яхшы сөйләшә иде һәм бу аны халыкка тагын да ныграк якынлаштырды. Ул бик гади һәм демократ кеше иде һәм үзе турында бик яхшы истәлек калдырды.

Әтиләрен күмгәч өч көннән соң Люда кайтты. Барыбыз бергә тирән кайгы кичердек , үз хәлебез турында киңәштек тә Москвага күчеп китәргә булдык.

Без бөтенләй акчасыз калдык; бервакытта да безнең җыеп барган акчабыз булмады. Ирем пенсиягә чыгарга бер ел калгач үлде һәм шуның өчен безгә аена нибары ун сум пенсия билгеләделәр. Мин тулы пенсия билгеләүне сорап Петербургка,

Володя Маяковский, Кутаис гимназиясенең 3 класс укучысы. 1905 ел.

урманчылык департаментына гариза язып җибәрдем. Өйдәге мебельләрне сатып бетердек һәм шуның белән тамак туйдырып тордык.

Кавказда безнең агай-энеләр һәм дуслар күп иде. Без грузиннар белән бик дуслаштык һәм алар белән бик тату тордык. Грузияне ташлап китү безгә бик кыен булды, без аның халкын, аларның гореф-гадәтләрен яраттык. Безгә анда грузиннар аеруча яхшы мөнәсәбәттә иделәр.

Грузиннар арасындагы ул тормыш турында бик яхшы истәлек бездә әле хәзер дә саклана.

Әйберләребезне сатып һәм яхшы танышлардан юлга ике йөз сум акча бурычка алып, без Москвага киттек. Безнең мәрхәмәтле танышыбыз: «Ул бурычны балаларыгыз укып чыккач кына бирерсез» дип безне озатып калды.

Шулай итеп без ерак, билгесез юлга чыгып киттек. Безне барлык туганнарыбыз һәм танышларыбыз озатып калдылар. Тифлиста минем апам Мария Алексеевна Агачева белән һәм дуслар белән хушлаштык.

Тифлиста без өч көн тордык, өч көн буена Володя шәһәр белән танышып йөрде. Тифлис аңа бик ошады, һәм ул шәһәрне зур кызыксыну белән карады.

Нефть шәһәре — Баку аша үткәндә күзгә вышкалар чагылып калды. Володя поезд туктаган саен чыгып карады, бөтен нәрсә белән кызыксынды. Без почта поезды белән барганга, ул станцияләрдә шактый озак торды.

Кавказ да, таулар да артта калды.

Дон елгасын (җәй көне саекканлыктан, ул безгә сай һәм тар булып күренде), Ростов-Дон шәһәрен үттек. Станцияләрдә бизәкле ситсы сарафаннар, чигүле күлмәкләр кигән крестьян хатыннары очрадылар...

Без инде Россиядә.

Тигезлек. Рус авылларын, крестьяннарның каралып беткән салам түбәле кечкенә өйләрен күрәбез. Вагоннарга чабаталы крестьяннар, ситсы яулык бәйләгән хатыннар керәләр. Кырда хатыннар, бөгелеп, урак белән бодай уралар.

Воронеж һәм Рязань шәһәрләрен үттек, дулкынлану белән Москвага якынлаштык. Алда бөтенесе дә яңа һәм ят иде.

Москвада Кавказдагы танышыбыз Плотниковларга, аларның Петровка-Разумовскидагы дачаларына тукталдык. Алар безне алып килгән Петербург поезды биш кенә минутка туктала торган платформада каршыладылар. Әйберләрне вагоннан чыгарышырга Володя бик тырышып ярдәм итте.

Шулай итеп, 1906 елның 1 нче августында без бөтенләйгә Москвага күчеп килдек. Козихинский тыкрыгы почмагындагы Кече Бронна урамында Ельгинский йортының өченче катындагы квартирага урнаштык.

Буш квартирага килеп кердек. Иң кирәкле мебельләр алу өчен танышлардан акча алып торырга кирәк иде. Кайбер әйберләрне танышларыбыз бирде.

Тормыш кору кыен булды. Зур шәһәр үз тормышы белән бара, һәм без миллион кешеләр арасында үз тормышыбыз өчен, киләчәк өчен көрәшергә булдык.

Пенсияне арттыру турындагы эшне тикшертү өчен мин Петербургка киттем. Дәүләт милке министрлыгы аркылы пенсия алуда миңа иремнең абыйсы, Михаил Константинович Маяковский ярдәм итте. Ул Тифлистан лесничий итеп Беловеж урманчылыгына җибәрелгән иде һәм Польшада Пружан дигән урында тора иде. Ул миңа Петербургка барырга кирәк дип хәбәр итте. Бик күп мәшәкатьләрдән, кыенлыклардан, күп сөйләшүләр һәм күндерүләрдән соң бөтенебезгә аена илле сум пенсия билгеләделәр.

Петербургтан кайтканда мин юлда үпкәм шешеп авырдым һәм озак авырып яттым.

Мин авырып ятканда Михаил Константиновичның көтмәгәндә үлеп китүе турында Польшадан телеграмма алдык.

Мин Володяга:

— Хәзер Маяковскийлар фамилиясен бердәнбер йөртүче варис булып син калдың,— дидем.

Бервакыт, Володя кечкенә чакта (ул чакта аны кулда гына күтәреп йөртә идек әле), Михаил Константинович: «Безнең фамилиянең варисы менә кем булыр!» дигән иде һәм шулай булды да.

Квартира кыйммәткә төште. Безгә өч бүлмәнең берсен кешегә бирергә киңәш иттеләр. Безгә Люданың танышы, грузин урнашты. Ул күп тә үтми китте, ә үз урынына иптәшен — икенче курс студенты грузинны — социал-демократны урнаштырып калдырды.

Люда Строганово училищесының өченче курсына күчте, Оляны танышыбыз Медведевлар Ежованың хосусый гимназиясенә урнаштырдылар, ә Володяны бишенче классик гимназиянең дүртенче классына укырга алдылар. Бу гимназия Поварский урамы почмагында иде (хәзерге Воровский һәм Зур Молчановка урамы).

Володяны Москва тормышы бик кызыксындырды, бу тормыш турында ул элек сөйләүләрдән һәм китаплардан укып кына белә иде.

Ул вакытта шәһәрнең үзәк урамнарында трамвайлар, ә башка урамнарда атлар җигелгән транспорт йөри иде. Извозчиклар бик күп иде. Володя күбрәк Тверской, Садовой һәм башка урамнар, тыкрыклар буйлап Москваны, аеруча зур шәһәрдәге кешеләрнең тормышын дикъкать белән өйрәнеп, җәяү йөри торган иде.

Москвага килгәч, Володя да, Оля да төп Москва кешесе, Люданың дус кызының туган энесе Медведев белән дуслаштылар һәм ул аларны Москва белән таныштырды.

Медведев өченче гимназиядә Володядан ике класска югары укый иде. Володя белән бергә алар кинога йөриләр иде. Кино сәнгате Володяны бик кызыксындырды, ул аның белән мавыкты, ләкин акча булмаганлыктан, кинога еш йөри алмады. Кинематографлар ул вакытта аз иде, картиналар бар да тавышсыз булып, начар күрсәтеләләр иде.

Володя Оля белән Строганово училищесы янындагы рәсем ясарга өйрәнү буенча кичке курсларга йөрделәр. Алар анда шулкадәр уңышлы укыдылар ки, хәтта укытучы Маслин аларга котлау хаты җибәрде.

Люда агачтан төрле әйберләр: тартмалар, пасха йомыркалары, шкатулкаларны кызган тимер белән көйдереп рәсемнәр ясау буенча эш таба иде.

Володя рәсемнәрне яхшы ясый иде. Кутаиста вакытта ук ул көйдереп агачка рәсемнәр ясый белә иде. Ул бу эштә апасына булышты, ә эшләнгән әйберләрне иртән магазинга илтеп тапшырды, чөнки Люда Строганово училищесына ашыга иде. Бу хезмәткә бик начар түләнде, ләкин эш һәрвакыт булып тора иде.

Кыш җитте, бөтен җир калын кар катлавы белән капланды. Каты суыклар башланып китте. Урамнарда чаналар күренделәр.

Кыш җитүгә балалар сөенделәр, алар чаналарда, конькиларда, чаңгыларда шудылар.

Кавказда салкын кыш булмаганлыктан, кышкы уеннар безгә таныш түгел иде. Монда, төньякта, бар нәрсә дә кызык һәм яңа иде. Ләкин Володяны барыннан да бигрәк яңа танышлар һәм күршедәге студентлар тормышы кызыксындырды. Ул еш кына аларның бүлмәсенә керде, китаплар алды, аларның сөйләшүләрен һәм бәхәсләрен тыңлады. Анда листовкалар, прокламацияләр, легаль һәм легаль булмаган китаплар укыдылар, революция турында, патша хөкүмәтен, алпавытлар һәм буржуаз хөкүмәтне бәреп төшерергә хәзерлек бару турында сөйләштеләр.

Мин, Володя студентлар янына кереп йөреп, аларга комачауламыйммы икән, дип борчылдым, ләкин алар миңа: «Володя төпле малай, күп укый һәм ул безгә комачауламый»,— диделәр.

Бу вакытлар турында Володя үз биографиясенә түбәндәгечә язды:

«Хикәяләрне, романнарны бөтенләй бар дип тә белмәдем. Философия. Гегель. Табигать белеме. Ләкин башлыча марксизм. Минем өчен Маркснның[1] «Сүз башыннан»да ныграк кызыксындырган сәнгать әсәре юк иде. Студентлар бүлмәсеннән легаль булмаган нәрсәләр тарала. «Урам сугышы такти-

[1] К. Маркснның «Политэкономияне тәнкыйть итүгә карата» дигән китабына сүз башы. Бу сүз башында тарихны материалистик аңлауның төп сызыклары язылган һәм җәмгыятьнең капитализмнан социализмга котылгысыз үсүе күрсәтелгән.

касы» һ. б. Ленинның зәңгәр тышлы «Ике тактика»сын[1] мин бик яхшы хәтерлим. Китапның хәрефенә кадәр ышкылып бетүе ошады. Легаль булмаган агарту өчен. Максималь экономия эстетикасы».

Безгә еш кына 1905 елны баррикадаларда сугышучы һәм Бауманны күмү демонстрациясенә катнашучы студентлар һәм курсларда укучы кызлар килә торганнар иде. Бу дулкынландыргыч кызыклы сөйләшүләр Володяны мавыктыра иде. Ул кешеләрнең бөтенесен яхшы белә һәм аларның ни турында сөйләүләрен аңлый иде.

Володя унөч яшьтә вакытта физик яктан үсү һәм берничә яшькә зур булып күренү генә түгел, ул аңы белән дә үскән иде: Володя бик белемле, җитди, өлкән классларның алдынгы укучылары һәм студентлары белән аралаша ала иде.

Безнең семьяга таныш булган Иван Богданович Караханов, Володя аңа укырга йөргән вакытлар турында үзенең истәлегендә Володяны бик җитди, уйланучан, политик яктан тулы белемле, революцион эш өчен хәзерлекле иптәш, дип характерлады.

Володя балалар арасында иң кечкенәсе булса да, мин һәм семьяның башка членнары аңа олы кешегә караган күк итеп карадык. 1905—1906 елларда Кутаиста вакытта ук ул зурлар кебек үзлегеннән эш итә ала торган иде һәм үзен карап йөртүгә мохтаҗ түгел иде.

Яз килде. Москва елгасыннан калын бозлар акты. Моны күрү безнең өчен бик күңелле булды, чөнки Кавказда елгалар туңмый.

Беренче уку елы тәмамланды. Җәйгә берәр җиргә урнашырга кирәк иде. Бу турыда безгә Кавказда чагында ук таныш булган Коптевлар ярдәм иттеләр. Алар дачага киттеләр

---

[1] В. И. Ленинның «Социал-демократларның демократик революциядә ике тактикасы» дигән китабы. Бу китапта меньшевиклар тактикасына классик тәнкыйть һәм буржуаз-демократик революция чорында большевиклар тактикасына гениаль нигез бирелгән.

һәм җиде яшьлек малайларын укыту өчен Оляны да үзләре белән алып киттеләр, ә җәй буе торыр өчен квартираларын түләүсез безгә калдырып киттеләр.

Володя Москва тирәләрендә йөрде, рәсемнәр ясады. Буага барып иптәшләре белән көймәдә йөрде. Күп укыды һәм латин теле буенча яңадан имтихан бирергә хәзерләнде.

Люда җәйгә «Новости дня» газетасы редакциясенә эшкә керде. Ул авыр шартларда, төнлә эшләде. Хуҗа аңа эш хакын вакытында түләмәде, ә соңыннан бөтенләй бирмәде — банкротлыкка чыкты.

Август аенда без Өченче Тверской-Ямской урамындагы квартирага күчтек. Бу квартираның ике бүлмәсендә студентлар торды, алар элек бездә торган иптәшләрен беләләр иде. Алар янына да шулай ук революционер иптәшләре килеп йөриләр иде. Володя элеккечә үзенең бөтен буш вакытын шушы революцион яшьләр белән үткәрде.

Володя студентлар һәм апалары белән студентлар кичәләренә йөрде. Ул анда Горькийның «Давыл хәбәрчесе турында җыр», «Лачын турында җыр» һәм башка революцион шигырьләрен һәм хикәяләрен укыды. Анда студентларның революцион җырларын җырлыйлар иде.

Володя үзенең иптәшләреннән һәм китапханәдән алган политик һәм фәнни әдәбиятны бик тырышлык белән укыды.

Иртән, йокыдан тору белән, ул:

— Газета бармы?— дип сорый торган иде.

Ул гимназиягә укырга йөрде, ләкин күбрәк башка эшләр белән шөгыльләнде: укыды, эшчеләр арасында пропаганда алып барды. Аңа ундүрт яшь тулды.

1907 елның азагы иде.

Безнең квартира очрашулар урыны булып китте, бездә партияле иптәшләр очрашалар иде. Революцион эш турында сөйләшү өчен полициядән яшеренеп, икешәр-өчәр кеше булып, аерым-аерым килә торганнар иде. Алар бездән яшерен әдәбият — листовкалар, прокламацияләр алалар яки үзләре белән алып килә торганнар иде. Болар инде барысы да зур иптәш-

ләр, профессиональ революционерлар иде. Володя да алар арасында бертигез кебек иде.

Кавказдан булган якташ иптәшләр белән безнең танышлыгыбыз тукталмады, киресенчә, ул ныгый гына барды.

Безнең квартирада Сухумнан килгән Туркиянең сеңелләре тордылар. Алар янына грузин студентлары килеп йөриләр иде. Соңгарак бездә Алексеев-Месхиевлар, курста укучы Ершова торды. Кутаистагы танышларыбыздан агалы-энеле Ставраковлар да безгә керәләр иде. Без алар белән дусларча, яхшы мөгамәләдә булдык. Москва кешеләре белән дә дуслаштык.

Бервакыт бездә квартирада консерватория студенты Николай Иванович Хлестов торды. Володя һәрвакыт аннан:

— Я, Коля, син миңа «О, бирегез, бирегез миңа ирек!» дигән җырны җырлап җибәр әле,— дип сорый торган иде.

Бу арияне Володя бик ярата торган иде. Шулай ук Шуманның Гейне сүзләренә язылган «Мин үпкәләмим», Римский-Корсаковның «Хәбәр йөртүче» дигән романсларын һәм бигрәк тә рус такмакларын һәм җырларын ярата иде.

Безгә, һәрвакыттагыча, яшьләрнең зур җәмгыяте җыела торган иде. Алар арасында иң кечкенәсе Володя иде. Бервакыт минем бер таныш хатыным: «Володяга ничә яшь?» дип сорады һәм аңа әле ундүрт кенә яшь дигәч, ул шаккатты. Әлеге хатын киткәч, Володя үпкәләп миңа болай диде:

— Миңа ничә яшь икәнне нигә әйтергә кирәк иде!

Ул үзен унҗидә яшьтә дип йөрде. Буй-сыны аны шулай күрсәтә иде, һәм аның тизрәк зур кеше буласы килә иде. Володя бик җитди, максатка омтылучан булды, аның балачагы күптән үткән иде инде.

1908 елда ул Россия социал-демократ эшчеләр (большевиклар) партиясе сафларына керде.

Партиягә кергәч, Володя миннән гимназиягә барып документларын алып кайтуымны сорады, чөнки, әгәр аны кулга алсалар, башка уку йортларына алмау хокукы белән, гимназиядән куып чыгарачаклар иде.

МОСКОВСКОЕ ОХРАННОЕ ОТДѢЛЕНІЕ.

Маяковскій Владими[р] ...ичъ 3037

ОПИСАНІЕ ПРИМѢТЪ.

Возрастъ по нар. виду 17-19 Годъ и мѣс. рожденія 7 июля 1893 г.
Ростъ 1 метръ сант. Полнота Тѣлосложеніе Объемъ въ поясѣ
1) Волосы: Цвѣтъ Волнистость Густота Лысина
2) Борода и усы: Цвѣтъ Форма Густота Особ.
3) Лицо: Цвѣтъ Полнокровіе Выраженіе Особ.
4) Лобъ: Высота Накл. Морщины Форма головы
5) Брови: Цвѣтъ Форма Густота Расположеніе Особ.
6) Глазныя впад. (орбиты): Величина Глубина Особ.
7) Глаза: Цвѣтъ райка Классъ Особ. Разст. между глазъ
8) Носъ: Спинка Основаніе Выст. Длина Шир. Особ.
9) Ухо: Форма Оттопыренность Велич. Особ.
Уши {10) борд.: Нач. Верх. Низ. 12) Противо-коз.: Накл. Проф. Выс.
{11) мочка: Накл. Форма Приростаніе 13) Внутр. скл. Вып. Велич.
14) Губы: Форма Высота Толщина Выступаніе Особ.
15) Подбородокъ: Длина Накл. Форма Полнота Особ.
16) Плечи: Ширина Накл. Шея Особен.
17) Руки: Величина Привычка держать Особен.
18) Ступни ногъ: Длина (№ обуви) 10-11 Особенность формы ногъ
19) Осанка (выправка корпуса. Манера держаться): свободно
20) Походка:
21) Особ. въ жестикуляціи, гримасы, мимика, и т. п.

Подпись

3) Во весь ростъ, стоя, въ 3/4 въ томъ самомъ головномъ уборѣ, верхн. платьѣ и обуви, въ котор. былъ задержанъ. Если носитъ очки, то одѣть.

В. Маяковскийның Москва охранкасындагы «карточкасы».

Володя еш кына кичләрен каядыр чыгып китә һәм өйгә бик соң гына кайта торган иде. Партия кушуы буенча ул эшчеләр арасында пропаганда эшләре алып бара иде.

Күп тә үтмәде, ул большевиклар партиясе Москва Комитетының яшерен типографиясе эше буенча кулга алынды һәм җавапка тартылды.

Аны 1908 елның 29 мартында, РСДРП (большевиклар) ның



В. Маяковский — Строганово промышленность-художество училищесы укучысы. 1910 ел.

Москва Комитетының яшерен типографиясе урнашкан Ново-Чухнинский тыкрыгындагы Грузинада кулга алдылар. Типографияне тентегәннән соң һәм эшче-большевик, подпольщик Трифоновны кулга алганнан соң, полиция анда засада оештырды.

Володя гимназия формасындагы киемнәрне кимичә, бер иптәше биргән озын пальто белән бүрек киеп йөри иде. Шушы пальтосын һәм папахасын киеп йөргән вакытта аны кулга алалар.

Володя Сущевскидагы кулга алу йортына ябылды. Аннан соң аны, яшь булганлыктан, эшен судта караганга кадәр дип, ирекккә чыгардылар.

Ирекккә чыгу белән Володя партия эшен, подполье эшен дәвам иттерде. Аның артыннан полиция нык күзәтте һәм аңа «Высокий» дигән кушамат бирде.

Өйдән ул бүреген кия-кия җырлап чыгып китә торган иде:

> Шәп булмас ул тегермәнче,
> Әгәр теләсә үлгәнче
> Өйдә генә торырга...

Берникадәр вакыт узгач, 1909 елның январенда, Володя икенче тапкыр кулга алынды, ләкин гаебен исбат итә алмаганлыктан, аны бик тиз ирекккә чыгардылар.

Володяның һәм аның белән бәйләнештә булган иптәшләренең тормышлары патша хөкүмәтенә каршы көрәштә ирек өчен, гадел, бәхетле, яхшы тормыш өчен көрәштә үтте.

Володя андый тормышның килүенә үзе нык ышанды һәм башкаларны да ышандырды. Безнең бөтенебез өчен дә яхшы булачак киләчәк тормыш турында ул миңа еш кына сөйли торган иде.

Володя эшсез тора алмады. Төрмәдән чыгу белән үк ул Строганово художество-промышленность училищесына укырга керде һәм шул ук вакытта партия эшен дә алып барды.

Училищеда ул тырышып укыды, ләкин ярты ел да үтмәде, ул яңадан кулга алынды.

Өченче тапкыр аны 1909 елның 2 июлендә, Новинский

бульвардагы хатын-кызлар төрмәсеннән унөч политкаторжанка качу уңае белән кулга алдылар. Новинский төрмәсендә утыручы политкаторжанкаларга булган зур теләктәшлек бездә патша төрмәчеләреннән аларны коткаруда ярдәм итү теләге тудырды.

Бу качуны оештыруда без кулдан килгән ярдәмне күрсәттек: качкын хатын-кызлар өчен гимназия формасында күлмәкләр тектек. Шушы эш белән йөргәндә Володя кулга алынды.

Ул 1910 елның 9 январена кадәр төрмәдә утырды. Аны бер полиция бүлегеннән икенчесенә күчереп йөрттеләр — Басманныйга, Мещанскийга, Мясницкийга, ә соңыннан Бутырка төрмәсенә күчереп, 103 номерлы ялгызлар камерасына яптылар.

Полиция аны өч елга Нарым краена җибәрмәкче булды. Минем бик күп тырышлык күрсәтүем сәбәпле һәм аның яшь



Москвада 1909 елда В. Маяковский яткан Бутырка төрмәсенең 103 номерлы ялгызлар камерасы.



В. В. Маяковский. 1911 ел.

булуын искә алып, Володяны ирекккә чыгардылар һәм полиция күзәтүе астына алдылар.

Төрмәдә Володя күп укыды һәм революцион шигырьләр язды. Төрмәдән чыкканда аның шигырьләр язган дәфтәрен алып калдылар. Аның рәсемнәр ясау белән шөгыльләнергә һәм «Социалистик сәнгать булдыруга» карар кылуы шушы вакытларга туры килә. Аңа ул вакытта уналты яшь иде.

Сын, архитектура, рәсемнәр ясау училищесына хәзерләнү өчен Володя художник-реалист П. И. Келинның студиясенә укырга керде һәм бик тырышып укыды. Аның турында художник Келин әйткәнчә, Володя студиягә беренче булып килә һәм иң ахырдан китә торган иде. Ул бервакытта да альбомын калдырмады һәм аңа нинди дә булса рәсемнәр ясады. Ул портретларны һәм карикатураларны бик әйбәт итеп ясый торган иде.

Володяның элекке укытучысы П. И. Келин, күп еллар үткәннән соң, 1943 һәм 1944 елларда аның ике портретын ясады. Алар Москвада Маяковскийның китапханә-музей йортында саклананалар.

Володя 1911 елны сын, архитектура, рәсемнәр ясау училищесына укырга керде.

Биредә ул тагын шигырьләр яза башлады. Аның киләчәк яңа тормыш хакында яңа сүзләр белән шигырьләр язасы килә иде.

1912 елны шушы училищеда укыганда аның беренче шигырьләре басылып чыга башлады.

Училищеда яңа һәм иске сәнгать турында бәхәсләр була торган иде. Художниклар группаларга бүленделәр. Берәүләре яңа сәнгатьне, икенчеләре искене яклыйлар иде.

Володя буржуаз сәнгатькә каршы иде. Буржуаз сәнгатькә ихтирам итмәгәне һәм аңа каршы кискен чыгышлары өчен аны 1914 елның февралендә училищедан чыгардылар.

Володя шигырьләрне торган саен күбрәк язды һәм бастырып чыгарды. Бервакытны ул миңа:

— Минем өстәл өстендәге кәгазь кисәкләренә, папирос

тартмаларына сүзләр һәм шигырь юллары язылган, алар миңа кирәк, сез аларны җыеп алып ташлый күрмәгез,— диде.

— Художество уку йортын тәмамласаң, яхшырак булыр иде,— дидем мин аңа.

Володя шаяртулы тон белән миңа болай дип җавап бирде:

— Рәсемнәр ясау өчен мастерская, киндер, буяулар һәм башка нәрсәләр кирәк, ә шигырьне куен дәфтәренә, мондый дәфтәргә, теләсә кайда язып була. Мин шагыйрь булам.

Мин аның беренче шигырьләрен укып карагач: «Боларын басмаслар» дигән идем, моңа каршы Володя ышаныч белән:

— Басарлар!— диде.

Аның әдәбиятка аяк басуын буржуаз җәмгыять дошманлык һәм шау-шу белән каршы алды: газета һәм журналларда аны әрли-тирги башладылар. Аларга яшь, ялкынлы шагыйрьнең яңа эчтәлекле шигырьләре һәм шигырьләр язу формасы ошамады. Ә бит ул вакытта Володя бу яңа эчтәлекләр һәм формалар өстендә тырышып эшләде һәм бирелеп эзләнде.

Володя әдәбият кичәләрендә еш кына чыгышлар ясады. Бай, буржуазия халкы аның чыгышларын бер дә яратмады. Алар шагыйрьгә ташландылар, аны сүктеләр. Ләкин Володя бурычлы булып калмады, аларга тапкыр һәм кискен җаваплар бирде, яки үзенең буржуазиягә каршы юнәлтелгән шигырьләрен укыды.

Галеркада утыручы демократик яшьләр аның шигырьләренең иске җәмгыятьне җимерүгә чакыруын сизеп, шагыйрьгә зур ышаныч һәм кызыксыну белән карадылар.

Гадәттәгечә беренче рәттә полиция һәм аларның башлыгы утыра иде, ләкин алар нәрсә җитди, нәрсә көлке икәнен күп вакыт аңлап җиткермиләр иде.

Минем: ник син шулай бөтенесе дә аңлашылырлык итеп язмыйсың, дип соравыма, Володя болай җавап бирде:

— Әгәр бөтенесен дә ачык итеп язсам, мин Москвада түгел, ә кая булса Себер сөргенлегендә, Туруханскида булыр идем. Мине эзәрлеклиләр, мин ачыктан-ачык: «Бетсен патша хөкүмәте!» дип кычкыра алмыйм ич инде.

В. Маяковский Киев шәһәрендә. 1913 ел.

Ләкин ул 1915 елда язган «Чалбар кигән болыт» дигән поэмасында бу турыда аеруча ачык әйтте:

Мин,
озын,
әшәке анекдот кебек,
бүгенге ыру алдында калучы көлкегә,
Торам,
вакыт таулары аша килүчене күреп,
кайсысын күрми беркем дә.

Кешеләрнең көтек карашы туктаган җирдә өзелеп,
ач урдалар башын калкытып, ул,
революциянең чәнечкеле таҗы белән бизәлеп,
килер, килер уналтынчы ел.

Патша власте вакытында, буржуазия яшәгәндә аның шигырьләре басылса да, аларның революция якынлашу турындагы юллары алып ташлана, нокталар белән алыштырыла иде.

Бу вакытта Володя Россиянең күп кенә шәһәрләрендә булды, әдәбият кичәләрендә үзенең шигырьләрен укыды, докладлар ясады. Ул бигрәк тә Москвада бик күп чыгышлар ясады, ләкин мин бу кичәләрдә булмадым. Володяның апалары анда булалар иде.

Володя миңа болай ди торган иде:

— Әнкәй, мин сезнең мине әрләгән, миңа һөҗүм иткән кичәдә булуыгызны теләмим, анда сезгә уңайсыз булыр, һәм сез борчылырсыз.

Ләкин кайбер кичәләргә ул мине дә чакыра иде. Һәм, Володяның чыгышларын тыңлап, мин аның үз карашы белән, гүя, бөтен җир шарын, көчләү һәм гаделсезлектән җәфаланучы бөтен кешелекнең тормышын чолгап алырга теләгәнен күрә һәм сизә идем.

Беренче бөтендөнья сугышы башланды.

Бу борчулы вакыт иде. Патша хөкүмәтенә каршы һәм халыкка кирәге булмаган империалистик, кешелексез сугышка каршы нәфрәт халыкта үскәннән-үсә барды.

1915 елда Володя Петроградка китте. Ул хәрби хезмәткә



А. М. Горькийның В. В. Маяковскийга бүләк иткән «Балачак» китабына язылган автографы.

алынды һәм автомобиль мәктәбендә хезмәт итте. Биредә дә ул әдәбият белән шөгыльләнүен дәвам итте.

Без һәрвакыт хатлар алышып тордык. Ул еш кына безгә кайта һәм Алексей Максимович Горький белән танышуын сөйли иде. Моның өчен без бик сөендек.

А. М. Горький яшь шагыйрь Маяковскийга зур бәя бирде һәм аның «Сугыш һәм тынычлык» исемле поэмасыннан бер өзекне «Летопись» журналында бастырып чыгарды.

Ул вакытта Алексей Максимович Володяга «Балачак» исемле китабын бүләк итте. Китапка ул болай язган иде:

«Сүзсез, чын күңелемнән.

Владимир Владимирович Маяковскийга.

М. Горький».

М. Горький кулы белән язылган истәлекле китапны ул Петроградтан алып кайтты һәм минем аны саклавымны сорады, чөнки ул күп йөргәнлектән аны югалтудан курыкты.

1917 елның февралендә патша хөкүмәте бәреп төшерелде. Эшчеләр һәм солдатлар баш күтәрделәр, патша хөкүмәтен кулга алдылар. Монархия бетерелде.

Володя революцион вакыйгаларга автомобиль мәктәбе укучылары белән бергә катнашты, бу переворот турында шигырьләр язды.

Володя революциянең болай гына туктап калмаячагын, киләчәктә буржуазиянең дә бәреп төшереләчәген, ягъни социалистик революция булачагын яхшы белде һәм аңа нык ышанды.

1917 елның 7 ноябрендә дөнья-күләм тарихи әһәмиятле вакыйга булды — Бөек Октябрь социалистик революциясе көне килде. Володя бу көнне үзенең тормышында иң якты, иң бәхетле көнем дип санады.

Ул революцияне тәбрик итте һәм аны: «Минем революциям» дип атады.

Үзенең автобиографиясендә ул болай дип язды:

«Октябрь. Кабул итәргәме яки кабул итмәскәме? Минем

В. В. Маяковский Парижда. 1925 ел.

В. В. Маяковский РОСТАда эш вакытында. А. Нюренберг рәсеме.

өчен мондый сорау... булмады. Минем революциям. Смольныйга киттем. Эшләдем. Нәрсә туры килсә, барысын да эшләдем».

Совет власте төзелүнең беренче көннәреннән үк ул үзенең бөтен хезмәтен яңа юлга аяк баскан Ватанга бирде.

Володя берникадәр вакытка Петроградтан Москвага кайтты, биредә ул Октябрь революциясенә багышланган яңа шигырьләрен укыды. Кино өчен сценарийлар язды һәм аларда баш рольләрне үзе уйнады. Бу эш уңышлы булды, кино сәнгате аңа ошады.

1919 елда Петроградтан Москвага кайтканнан соң, Володя фронт өчен эшли башлады: шигырьләр язды һәм «РОСТАның сатира тәрәзәсе» өчен плакатлар ясады. Гражданнар сугышы елларында бу зур плакатларны Россия телеграф агентлыгы

урамнарга элеп куя торган иде. Күзгә ташлана торган сатирик рәсемнәр һәм шигырь белән язылган сугышчан лозунглар халыкны дошманга каршы көрәшкә мобилизацияләделәр.

«РОСТА тәрәзәсе»ндә Володя тырышып эшләде, һәм без бөтенебез дә аңа ярдәм иттек: апалары бизәк төшерә торган өлгеләр ясадылар, рәсемнәрне ишәйттеләр, ә мин буяулар әзерләдем.

Бервакыт мин көтмәгәндә Любянкага аның янына кердем. Ул ашыгып эшләп ята иде. Аңа комачауламас өчен мин китәргә булдым. Ул мине бик ягымлы каршылады, тәмле әйберләр белән чәй эчерде, сөйләште, ләкин үзе эшен дәвам итте.

Володя өйгә безнең хәлне белергә килгәч:

— Әнием, мин сезгә бераз акча китердем,— ди торган иде ул миңа.

Володя сизгер, игътибарлы, яхшы мөгамәләле бала һәм туган булды, бөтенебезгә дә ярдәмгә килде һәм кыенлыктан коткарды.

Ул да, без дә һәрвакыт эштә булдык. Моннан соңгы елларда Володя күп йөрде, еш күрешергә туры килмәде. Шуның өчен аның һәрбер кайтуы бездә зур шатлык, дәртлелек тудырды һәм безгә яңалык китерде.

Ул бөтенесен дә үз күзе белән күрү, бәя бирү һәм үзенең тәэсирләрен шигырьләрендә чагылдыру өчен туган ил буйлап күп йөрде, чит илләргә дә чыкты. Ул гаять күзәтүчән һәм тәэсирләнүчән иде.

Чит илләрдә булып кайтканнан соң ул үзенең социалистик ватанын тагын да ныграк яратты һәм аның бу мәхәббәте «Совет паспорты турында шигырь» дигән әсәрендә бик ачык чагылган.

Володяның шигырьләре, поэмалары, бигрәк тә «Владимир Ильич Ленин» һәм «Яхшы» дигән әсәрләре аның халыкка, партиягә, юлбашчыларыбыз Ленин һәм Сталинга, коммунизм төзүгә бирелгәнлеге турында сөйли.

Аның «Утырышучыларга» дигән шигырен Владимир Ильич Ленинның мактаганын ишеткәч, ул бик рухланды һәм чынчыннан сөенде. Бу 1922 елда булды. Ленин сүзләре аңа эштә



В. В. Маяковский. 1928 ел.

ышанычлык бирделәр, сайланган юлы — шагыйрь-көрәшче юлының дөрес икәнен расладылар.

Күп еллар үтте. 1930 елның 21 гыйнварында Зур театрда В. И. Ленин истәлегенә багышланган тантаналы-кайгылы утырышта ясаган чыгышы турында Володяның безгә шундый дулкынлану белән сөйләвен һич тә оныта алмыйм. Бу кичәдә ул Ленин турындагы үзенең поэмасын укыды. Аның чыгышын иптәш Сталин, партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре тыңладылар.

Бу чыгышы турында ул безгә:

— Бу минем тормышымда иң җаваплы чыгышым булды,— диде.

Володя 1930 елның 1 февралендә Москвада күргәзмә оештырды. Бу күргәзмәдә ул үзенең гаять зур эшен — китапларын, газета һәм журналларда басылган шигырьләрен, рәсемнәрен күрсәтте.

Күргәзмәдә без дә булдык.

Володя безгә материаллар күрсәтте һәм:

— Шундый күп рәсемнәр ясаганмын һәм әсәрләр язганмын дип, мин үзем дә көтмәгән идем,— диде.

Революциядән соң мин дә улымның кичәләрендә еш кына булдым. Кайбер кешеләр аңа:

— Сезнең шигырьләрегез аңлашылмый һәм озак яшәмәсләр, аларны тиз онытырлар,— дип әйтәләр иде.

Моңа ул бервакыт болай җавап бирде:

— Ә сез мең елдан соң керегез, ул вакытта сөйләшербез.

Аңа әсәрләре аңлашылмый дип алдан күрә алмаучылар һәм дошман караштагы кешеләр генә әйттеләр. Аның әсәрләрен бастырып чыгаруга, пьесаларын сәхнәләрдә куюга, шигырьләрен укуга шундый кешеләр комачауладылар. Ә яшьләр һәм халык аны аңлый һәм ярата иде.

Халыкның Маяковский иҗатын яратуы мәңге онытылмаслык безнең Иосиф Виссарионович Сталин сүзләрендә чагылган:

«Маяковский безнең совет эпохасының иң яхшы, иң талантлы шагыйре булды һәм шулай булып калыр да».

В. В. Маяковский. 1929 ел.

Халык героинясы — комсомолка Зоя Космодемьянская Маяковский әсәрләрен укыды һәм кат-кат укыды. Аның шигырьләреннән Зоя үзенең уйларына, тойгыларына җавап тапты.

Совет яшьләре алдында, дөньяның прогрессив яшьләре алдында торган бурычлар турында фикер йөртеп, Зоя үзенең көндәлек дәфтәренә яраткан шагыйренең түбәндәге шигырь юлларын алып язып куйган:

Кемнәр көрәшчеләрнең
сирәгәйгән сафына
Барлык балалар
исеменнән дәшәр:
«Җирдәге тормышны үзгәртү хакына
киләбез!» дияр,
менә шулар яшьләр.

1941 елның көзендә Бөек Ватан сугышы фронтына киткәндә Зоя Космодемьянская куен дәфтәрен калдырган. Бу дәфтәргә девиз кебек итеп Маяковскийның мондый сүзләре кертелгән:

Коммунист булу —
кыю булу дигән сүз,
Уйларга,
теләргә,
омтылырга
дигән сүз.

Ул үзе шундый иде. Миллионнарча кешеләр — безнең илдә тенә түгел, бәлки бездән ерак чит илләрдә дә — Володяны шундый итеп беләләр һәм яраталар.

Москвадагы Маяковскийның китапханә-музеена кергән кешеләр отзывлар журналында калдырган язмаларында бу турыда гади итеп әйтеп бирәләр.

Бөек Ватан сугышында катнашучы берәү болай язган:

«Без, яшь буыннар, 1941—1945 елгы Бөек Ватан сугышы елларының авыр көннәрен үттек. Безне көрәшкә Ленин-Сталинның бөек партиясе алып барды. Һәм партия җырчысы — гениаль рус шагыйре Владимир Владимирович Маяковский һәр-

вакыт безнең белән булды. Бу очраклы түгел. Безнең халыкта булган барлык яхшы, якты, кыйммәтле яклар — болар барысы да Маяковскийның тормышында һәм иҗатында гәүдәләнде. Без Маяковскийны яратабыз. Һәм бу мәхәббәт сугышта да, хезмәттә дә безнең күпләребезгә ярдәм итте».

Ә менә совет мәктәбе укучыларының язмалары:

«Маяковский — ул безнең иң яраткан шагыйребез. Ул һәр көнне, һәр сәгатьтә безнең белән бергә, янәшәбездә бара. Ул безне әйләнә-тирәбездә булганнарның барысы турында да уйларга мәҗбүр итә, тормышны яхшырак күрергә һәм аңларга ярдәм итә.Ул безгә бик кадерле һәм аңлаешлы».

«Маяковскийның шигырьләре без яшьләрне яңа җиңүләргә, хезмәткә, шагыйрь үзенең шигырьләре белән көрәшкән коммунистик төзелешкә дәртләндерә».

«Без Владимир Маяковскийның безнең социалистик илдә яшәве һәм эшләве белән горурланабыз».

Бөек Горький сүзләре белән әйтәсе килә:

«Син үлдең ди... Ләкин кыюлар һәм көчлеләр җырында син һәрвакыт тере мисал булып, иреккә, яктылыкка горур чакыручы булып калырсың!»

Кытай Халык Республикасының әдәбиятчылары делегациясе Маяковскийның китапханә-музеен караганнан соң журналга түбәндәгеләрне язып калдырды:

«Кытай язучылары һәм шагыйрьләре Маяковскийдан аның үз шигырьләре белән бөтен дөньяда иминлек булдыру өчен көрәш үрнәкләрен өйрәнәләр һәм өйрәнерләр».

Чехословакия яшьләр союзының делегатлары, культура-пропаганда работниклары шундый язу язып калдырганнар:

«Маяковский безнең яшьләрнең иң яраткан шагыйре булды һәм шулай булып кала да. Безнең беренче коммунистларыбыз 20 нче елларда аның «Сул марш»ын укыдылар. Буржуазия республикасы елларында безнең комсомоллар Беренче май демонстрацияләрендә аның шигырьләрен декламация итеп сөйләделәр. Оккупация елларында безнең иптәшләребез Маяковский шигырьләрен концентрацион лагерьларда укыдылар. Ул шигырьләр безгә яңа көч бирделәр.

В. В. Маяковский Красная Пресня Қомсомол йортында. Март, 1930 ел.

Бүген дә Маяковский — безнең көч, безнең корал. Аның шигырьләрен яшьләр Остравский комбинаты төзелешендә декламация итеп сөйлиләр, ә пионерлар «Нәрсә ул яхшы һәм нәрсә ул начар» әсәрен укыйлар.

Без Маяковскийны яратабыз. Безнең республикадагы социалистик әдәбиятның һәрбер яңа чыккан әсәрендә Маяковскийга мәхәббәт сизелә, безнең иң яхшы китапларыбызда аның рухы яши. Боларның барысы өчен дә социалистик эпоханың иң яхшы, иң талантлы шагыйренә рәхмәт, ул яшәгән илгә рәхмәт, аны тәрбияләп үстерүче Коммунистлар партиясенә рәхмәт».

«Безнең дә аз санлы халкыбыз һәм безнең яшьләребез Маяковскийны беләләр, яраталар һәм аннан өйрәнәләр,— диелә Албания яшьләре делегациясе калдырган язмаларда.— Ул— революция һәм совет эпохасы шагыйре, ул — безнең киләчәкне дә җырлаган шагыйрь. Ул безнең халыкны да яратты. Ул «Албания белән баерга» теләүчеләргә каршы («Җавапка» дигән шигырь), үзенең тавышын «бомба һәм байрак» кебек итеп күтәрде. Без аңа рәхмәт әйтәбез, без Маяковскийны яраттык, яратырбыз һәм өйрәнербез. Киләчәк тормыш өчен көрәштә ул безнең белән».

Танылган төрек шагыйре һәм революционер Назыйм Хикмәт күп еллар төрмәдә ятып фашист тырнагыннан котылгач, Маяковскийга күптәнге һәм якын дусты итеп мөрәҗәгать итә:

«Бөек дус, бөек шагыйрь, өлкән кеше, минем зур абыем Маяковский!

Мин күп еллардан соң тагын синең көчле, намуслы кулыңны кысам. Юк, бу кул һәрвакыт минем кулымда. Бәхет өчен, ирек һәм киләчәк якты тормыш өчен көрәшүче барлык намуслы кешеләр үз кулларында синең кулыңны сизәләр. Син елдан-ел тагын да матуррак, тагын да куәтлерәк, тагын да көчлерәк була барасың...

Без синең белән горурланабыз, өлкән ага, сине яратабыз; без синнән өйрәндек һәм өйрәнербез».

Советлар Союзының барлык почмакларыннан, дөньяның барлык илләреннән Маяковскийның китапханә-музеена килү-

челәр язып калдырган шундый чын күңелдән әйтелгән кайнар сүзләрне мисалга бик күп китерергә мөмкин булыр иде.

Вакыт күбрәк үткән саен, бездәге һәм бөтен дөньядагы кешеләр Маяковскийның иҗатын күбрәк ихтирам итәләр һәм аңлыйлар.

Бу минем өчен зур бәхет булып тора.

Москва, 1952—1953

Бәясе 2 сум 35 тиен.